Уң ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал. Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр. Галәмәттән морадым бер догадыр».

Арткы ягы:
1) «32 яшендә
2) чәршәмбе көн
3) вафат Аллаһ рә-
4) -хим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 116x31x11.

14. Фәйзрахман Габделгалим улы Габделмәннафовка куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу каберә назил мәрхүм
3) Фәйзрахман Габделгалим
4) углы Габделмәннафыф
5) вафат 1913 сәнә миладиййә
6) март 20 ндә 40 йәшдә
7) рахимәллааһү рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлынгыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүм
3) Фәйзрахман Габделгалим
4) улы Габделмәннафов
5) милади 1913 елның
6) 20 мартында 40 яшьтә вафат.
7) Аллаһ киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Таш үлчәмнәре: 107x30x12.

15. Сиражеддин Шәмседдин улына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаһү ли-мән зәәрании
2) румиййә илә 1911 нче
3) йыл 22 нче агустда
4) Сиражеддин Шәмс-
5) -еддин углы 54
6) йәшендә mah шәриф-
7) -нең 11 ндә даре фәнада-
8) -н даре бәкайә рихләт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Ләһү мәләкүн йәнәәдии күллә йәүүм»[81].

Сул ягы (уеп язылган): «Лидүү лил-мәүти вә-бнүү лил-харарб»[82].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Милади белән 1911
3) елның 22 августында
4) Сиражеддин Шәмс-
5) -еддин улы 54
6) яшендә 11
7) -рамазанында фани дөньяда-
8) -н мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Көн саен фәрештә аңа кешегә әйтә».

Сул ягы: «Туыгыз – барыбер үләчәксез, биналар төзегез – барыбер җимереләчәк».

Таш үлчәмнәре: 93x30x12.

16. Бибизөләйха Гыйззәтулла кызына куелган кабер ташы, 1908 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Бибизөләйха Гыйззәтулла кызы
4) Шәмседдин Сәйфулла
5) углыйның зәүҗәсе 1908
6) нче сәнәи миладиййә 26 нчы
7) үктәбр 1326 hиҗриййә
8) шәүвәл 14 ндә 75 йәшендә
9) мәдфүнә нәүвәраллаһү кабраһәә әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Күрүб каберем әҗәлне әйләгел йад тәсаддыклә кыйлынгыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблә-әҗәл ән-нәдәәмәтү лә түфиидү бәгъдә-әҗәл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Бибизөләйха Гыйззәтулла кызы –
4) Шәмседдин Сәйфулла
5) улының хатыны – милади
6) 1908 елның 26
7) октябрендә, hиҗри 1326 [елның]
8) 14 шәүвәлендә 75 яшендә
9) җирләнде. Аллаһ аның каберен нурландырсын, амин».

Уң ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал. Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Әй, кардәшем, әҗәл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит. Әҗәл килгәч, тәүбә файда бирми».

Таш үлчәмнәре: 110x31x13.

17. Бибисабира Шәмседдин кызына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) руми 1903 сәнә синтәбр
3) 21 дә hиҗри 1321 сәнә
4) рәҗәб 14 дә Иске
5) Мәнгәрнең Бибисабира
6) Шәмседдин кызы»[83].

Уң ягы (уеп язылган): «Тайиибәллаһү сәраһәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә».

Сул ягы (уеп язылган): «Олуг Әтнәнең Хәбибулла Гайнулла углы»[84].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «зәүҗәсе 33 йәшдә
2) даре бәкайә рихләт кылды
3) галәмәтдән морадым бер догадур

[81] Дәвамы сул ягында.
[82] Башы уң ягында.
[83] Дәвамы сул һәм арткы якларында.
[84] Башы алгы, дәвамы арткы ягында.

4) бу көн бәндә икән йар-
5) -ин сәңадур»[85].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Милади 1903 елның 21
3) сентябрендә, һиҗри 1321 елның
4) 14 рәҗәбендә Иске
5) Мәңгәрдән Бибисабира
6) Шәмседдин кызы».

Уң ягы: «Аллаһ Тәгалә аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен».

Сул ягы: «Олы Әтнәдән Хәбибулла Гайнулла улының».

Арткы ягы:
1) «хатыны 33 яшьтә
2) мәңгелек дөньяга күчте.
3) Галәмәттән морадым бер догадыр,
4) бу көн миндә икән, иртә-
5) -гә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 103х32х14.

18. Шәмседдин Сәйфулла улына куелган кабер ташы, 1900 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгаләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми 1900 сәнә
3) април 20 ндә һиҗри 1317 сәнә
4) мөхәррәм 4 ндә Иске Мәнгәр-
5) -нең Шәмседдин Сәйфулла
6) углы пәнҗешәнбә көн»[86].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабер Иске Мәнгәрнең
2) Шәмседдин Сәйфулла
3) углының мәркадедүр»[87].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәрбер җан иясе
2) үлемне татыячак. Милади 1900 елның
3) 20 апрелендә, һиҗри 1317 елның
4) 4 мөхәррәмендә Иске Мәңгәр-
5) -дән Шәмседдин Сәйфулла
6) улы пәнҗешәмбе көн [вафат яки җирләнде]».

Арткы ягы:
1) «Бу кабер Иске Мәңгәрдән
2) Шәмседдин Сәйфулла
3) улының кабередер».

Таш үлчәмнәре: 80х37х13.

19. Габделвәли Халид улына һәм Бибигафифә Габденнасыйр кызына куелган кабер ташы, 1889 һәм 1901 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаләә
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Габделвәли Халид
4) углы 1889 нчы
5) йылда синтәбр 11 ндә
6) 60 йәшдә дарел-бәкайә
7) рихләт кыйлды Аллаһ рәхмәт
8) кыйлгай иде амин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Бибигафифә Габденнасыйр кызы
4) Габделвәли Халид углының
5) әһлийәсе 1901 сәнәи миладиййә
6) май 27 сендә 60
7) йәшдә мәдфүнә нәүвәр-
8) -аллаһү кабрһәә әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Габделвәли Халид
4) улы 1889
5) елның 11 сентябрендә
6) 60 яшьтә мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ рәхим
8) кылса иде, амин».

Арткы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Бибигафифә Габденнасыйр кызы –
4) Габделвәли Халид улының
5) хатыны – милади 1901 елның
6) 27 маенда 60
7) яшьтә җирләнде. Аллаһ аның
8) каберен нурландырсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 103х32х14.

[85] Башы алгы һәм сул якларында.
[86] Дәвамы арткы ягында.
[87] Башы алгы ягында.

20. Бибигайнеҗамал Сәйфелмөлек кызына куелган кабер ташы, 1882 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми 1882
3) сәнә синтәбр 15 ндә һиҗри 1299 сәнә
4) җөмадиәл-әүвәл 25 ндә Мамыш авылы
5) Галиәкбәр Иманколуфның зәүҗәсе Биби-
6) -гайнелҗамал Сәйфелмөлек кызы 62
7) йәшдә пәнҗешәнбә көн дарел-бәкайә»[88].

Уң ягы (уеп язылган):
1) «Ә-тәдрии әййү йәүмин зәәкә фәккир
2) вә әйкыйнь әннәһү йәүмүл-фираакый
3) фираакун ләйсә йүшбиһүһү фираак
4) кад инкатагар-раҗәәү ганит-тәләәкъ».

Сул ягы (калкытып язылган): «Рихләт кыйлды рахимәллаһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ»[89].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һәзәә кабру Гайнелҗамал бинте Сәйф-
2) -елмөлек хәлиләи Галиәкбәр әл-Ма-
3) -мыши әл-Иманколый гафийә ганһәә-
4) -л-Мәликүл-Гаалии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәрбер җан иясе
2) үлемне татыячак. Милади 1882
3) елның 15 сентябрендә, һиҗри 1299 елның
4) 25 җөмадиәл-әүвәлендә Мамыш авылыннан
5) Галиәкбәр Иманколовның хатыны – Биби-
6) -гайнеҗамал Сәйфелмөлек кызы – 62
7) яшьтә пәнҗешәмбе көн мәңгелек дөньяга».

Уң ягы:
1) «Беләсеңме ул кайсы көн, фикерлә
2) һәм ышан: ул – аерылу көне,
3) охшамаган ул аерылуга,
4) очрашу өметен өзде».

Сул ягы: «күчте. Аллаһ Тәгалә киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Бу – Гайнеҗамал бинте Сәйф-
2) -елмөлек – Галиәкбәр Мамыши
3) Иманколый хатыны – кабере. Патша, Олуг
4) зат аны кичерсен».

Таш үлчәмнәре: 110x35x18.

21. Габделхәким Муса улына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүм Габделхәким
3) Муса углы 1907
4) йыл априлдә 90 йә-
5) -шендә вафат
6) рахимәһүллаһү Тәгааләә
7) әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «Күллү мән галәйһәә фәән».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хәкем Аллаһта.
2) Мәрхүм Габделхәким
3) Муса улы 1907
4) ел апрелендә 90 я-
5) -шендә вафат.
6) Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын,
7) амин».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани».

Таш үлчәмнәре: 73(84)x30x9.

22. Маһитаб Габдессабир кызына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) Маһитаб Йаңа
3) Кишет Габд-
4) -ессабир кызы
5) Иске Кишет
6) Мөхәммәҗән Нәбийулла
7) углыйның зәүҗәсе».

[88] Дәвамы сул ягында.
[89] Башы алгы ягында.

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Тарих миладиййә
2) илә 1916 нчы
3) йыл 18 нче мартда
4) һиҗриййә илә
5) 1334 нче йыл
6) 53 йәшендә вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Маһитаб Яңа
3) Кишеттән Габд-
4) -ессабир кызы –
5) Иске Кишеттән
6) Мөхәммәҗҗан Нәбиулла
7) улының хатыны».

Арткы ягы:
1) «Милади
2) белән 1916
3) елның 18 мартында,
4) һиҗри белән
5) 1334 елда
6) 53 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 71(81)x31x9.

Иске Өҗем авылы зираты

1. Сабиржан Галимҗан улына куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбрah
2) Сабиржан Галимҗан
3) углы 1926 нчы
4) йылда май 10 нчы көне
5) 30 йәшендә җан
6) тәслим әйләде
7) Аллаһ рәхмәт әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Сабиржан Галимҗан
3) улы 1926
4) ел маеның 10 нчы көнендә
5) 30 яшендә җан
6) тәслим кылды.
7) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 92x32x12.

2. Фәхрежамал Габделгаффар кызына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иске Өҗемнең
2) Фәхрежамал бинте Габделгаффар
3) Хафиз җәмәгате руми
4) 1921 нче йыл 2 нче
5) фивралда 50 йәшендә
6) вафат нәүвәраллаahү кабраһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Иске Өҗемнән
2) Фәхрежамал бинте Габделгаффар –
3) Хафиз җәмәгате – милади
4) 1921 елның 2
5) февралендә 50 яшендә
6) вафат. Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Таш үлчәмнәре: 64x31x8.

3. Бибилатыйфа Һибатулла кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) бу каберә назилә Бибилатыйфа
3) Һибатулла кызы
4) Сәмигулла зәүҗәсе
5) һиҗриййә илә 1325 нче
6) мөхәррәм 3 ндә фиврал 3 ндә
7) миладиййә илә 1907 нче».

Уң ягы (уеп язылган): «Ән-нәәсү нийәәмүн изәә мәтүү интәбәһүү».

Сул ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллаahү мәркадәһәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә вә мәәъәһәә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәллаahү
2) йүхиббү хифзал-кадиим
3) вафат Бибилатыйфа
4) 70 йәшендә
5) йәә әхый гафил улма
6) сакыйн беләсез
7) бу кабер киләчәк
8) вакытыңыз йакын».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.

2) Бу кабергә Бибилатыйфа
3) Һибатулла кызы –
4) Сәмигулла хатыны –
5) һиҗри белән 1325 [елның]
6) 3 мөхәррәмендә, милади 1907
7) [елның] 3 февралендә иңде».

Уң ягы: «Кешеләр йоклыйлар, үлгәч уяналар».

Сул ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын һәм урынын җәннәт итсен».

Арткы ягы:
1) «Чынлыкта, Аллаһ
2) борынгылыкны саклаганны ярата.
3) Бибилатыйфа
4) 70 яшендә вафат.
5) Әй, кардәшем, гафил булма,
6) сак бул. Беләсез:
7) бу кабергә киләчәк
8) вакытыгыз якын».

Таш үлчәмнәре: 110(128)x32x16.

4. Сәмигулла Вәлиулла улына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) бу каберә назил Сәмигулла
3) Вәлийулла углы
4) һиҗрииә 1325 нче йылда
5) мөхәррәм 13 ндә фиврал 13
6) миладииә илә 1907 нче йылда
7) 73 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Ән-нәәсү нийәәмүн изәә мәтүү интәбәһүү».

Сул ягы (уеп язылган): «Иннәллааһү йүхиббү хифзал-кадиим иске әсәрне Аллаһ сөйә»[90].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Сәмигулла
2) Вәлийулла углы
3) галәмәтдән морад-
4) -ым бер догадыр бу кө
5) бәнд икән йарин
6) сәнгадыр
7) хосусан безем исла-
8) -мийәтемезне күрсәтә тор-
9) -ган иске әсәрләрне»[91].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Бу кабергә Сәмигулла
3) Вәлиулла улы
4) һиҗри 1325 елның
5) 13 мөхәррәмендә, милади белән
6) 1907 елның 13 февралендә
7) 73 яшендә иңде».

Уң ягы: «Кешеләр йоклыйлар, үлгәч уяналар».

Сул ягы: «Чынлыкта, Аллаһ борынгылыкны саклаганны ярата. Иске әсәрне Аллаһ сөя».

Арткы ягы:
1) «Сәмигулла
2) Вәлиулла улы.
3) Галәмәттән морад-
4) -ым бер догадыр, бу кө[н]
5) минд[ә] икән, иртәгә
6) сиңадыр.
7) Аеруча, безнең исла-
8) -мыбызны күрсәтә тор-
9) -ган иске әсәрләрне [Аллаһ сөя]».

Таш үлчәмнәре: 111x36x16.

5. Бибигазизә Бәдреддин кызына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бисмилләәһи Тәгаалә
2) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
3) Иске Өҗем авылыйның Сафийулла
4) Хәсбийулла углыйның җәмәгате
5) Бибигазизә Бәдреддин кызы
6) 1904 нче сәнә април 11 нче көне
7) 48 йәшендә җан тәслим
8) әйләде рахмәтүллаәһи рахмәтән вәәсигаһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр бу көн бәндә икән йарин сәнгадыр».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) вәгазь натыйк кирәксә
3) сәнга Коръән йитәр
4) вәгазь самит кирәксә
5) йәкфии ки табут кәфен
6) углы Заһидулла бина
7) кылдырды».

[90] Дәвамы арткы ягының ахыргы өч юлында.
[91] Ахыргы өч юллы җөмләнең башы сул ягында.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә исеме белән.
2) Һәр җан иясе үлемне татыячак.
3) Иске Өҗем авылыннан Сафиулла
4) Хәсбиулла улының җәмәгате –
5) Бибигазизә Бәдреддин кызы –
6) 1904 ел апреленең 11 нче көнендә
7) 48 яшендә җан тәслим
8) кылды. Аңа Аллаһның киң рәхмәте булсын».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Арткы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Вәгазь сөйләүче кирәк булса,
3) сиңа Коръән җитәр.
4) Телсез вәгазь кирәк булса,
5) табут, кәфен җитәр.
6) Улы Заһидулла
7) куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 106x31x13

6. Маһикамал Габдерәхим кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе
3) Иске Өҗем авылыйның
4) Гобәйдулла Нигъмәтулла у-
5) -глының җәмәгате Маһикамал
6) Габдеррәхим кызы 1910 нчы сәнә
7) фиврал 6 нчы көне 90 йәшендә
8) җан тәслим әйләде».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кә хөкмелла будыр ошбу фәнада
2) кә кимсә калмайа бакый ошбу фәнада
3) әгәр табсаң хәйәте Хозыр вә Илйас
4) китәрсен бу җиһандин әййүһән-нәс
5) әгәр табсаң хәйәте хәзрәти Нух
6) кыйлур бер көн үлем җаныңны мәхруҗ
7) углы Сибгатулла йазды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе
3) Иске Өҗем авылыннан
4) Гобәйдулла Нигъмәтулла у-
5) -лының җәмәгате – Маһикамал
6) Габдерәхим кызы – 1910 ел
7) февраленең 6 нчы көнендә 90 яшендә
8) җан тәслим кылды».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме будыр бу фани дөньяда,
2) Кеше калмас мәңге бу фани дөньяда.
3) Әгәр тапсаң [да] Хозыр һәм Ильяс гомерен,
4) Китәрсең бу җиһаннан, әй, кешеләр!
5) Әгәр тапсаң хәзрәти Нух гомерен,
6) Бер көн үлем җаныңны чыгарыр.
7) Улы Сибгатулла язды».

Таш үлчәмнәре: 99(109)x31x12.

7. Фәхрежамал Монасыйб кызына һәм Габделҗаббар Габдессаттар улына куелган кабер ташы, 1910 һәм 1915 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Иске Өҗем авылы
3) Габделҗаббар Габдессаттар
4) углы 90 йәшендә
5) 1915 нче йылда ийүл
6) 9 нда җан тәслим әйләде».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Фәхрежамал
2) Монасыйб кызы Габделҗаббар
3) бине Габдессаттар
4) җәмәгате 1910 нчы сәнә
5) март 3 ндә 70
6) йәшендә вафат итде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Иске Өҗем авылыннан
3) Габделҗаббар Габдессаттар
4) улы 90 яшендә
5) 1915 елның 9
6) июлендә җан тәслим кылды».

Арткы ягы:
1) «Фәхрежамал
2) Монасыйб кызы – Габделҗаббар
3) бине Габдессаттар
4) җәмәгате – 1910 елның
5) 3 мартында 70
6) яшендә вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 91x30x10.

8. Фәтхулла Нигъмәтулла улына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу каберә назил Иске
3) Өҗем авылыйның
4) Фәтхулла Нигъмәт-
5) -улла углы 64 йәшендә
6) һиҗриййә илән 1322
7) нче йылда 12 нче рабигыль-а-
8) -хирдә шинбә көн
9) тәслиме рух әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Үтте дәүран кичде сәйран бәне күр бәне күр дә килүр йарагын сәндә күр».

Сул ягы (уеп язылган): «Күрәрмен дөнйаны вәйран бары бакый ирмәс һичдә йук карары».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Румиййә илә 1904 нче
2) йылда 12 нче ийүндә
3) ахшам бәгъдендә
4) дарел-бәкайә һиҗрәт әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә иңүче Иске
3) Өҗем авылыннан
4) Фәтхулла Нигъмәт-
5) -улла улы 64 яшендә
6) һиҗри белән 1322
7) елның 12 нче рабигыль-а-
8) -хирендә шимбә көн
9) рух [җан] тәслим кылды».

Уң ягы: «Үтте дәвер, бетте күңел ачу, мине күр, мине күр дә килер өчен кирәк-ярагын син дә күр».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерек, һич тә мәңге булмас, юк карары».

Арткы ягы:
1) «Милади белән 1904
2) елның 12 июнендә
3) ахшамнан соң [кич]
4) мәңгелек дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 116x36x14.

9. Бибифатыйма Гобәйдулла кызына куелган кабер ташы, 1898 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Тарих румиййә илә
2) 1898 сәнә май 27 ндә
3) Иске Өҗемнең хаҗҗ-
4) -ел-хәрәмәйен Габденнасыйр хәләле
5) Бибифатыйма Гобәйдулла кызы
6) 80 йәшендә чәһаршәнбә көн
7) даре бәкайә интикаль»[92].

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Әйләде Аллаһ Тәгалә гарикы рәхмәт кыйлсун амин»[93].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Милади белән
2) 1898 елның 27 маенда
3) Иске Өҗемнән хаҗи
4) Габденнасыйр хәләле –
5) Бибифатыйма Гобәйдулла кызы –
6) 80 яшендә чәршәмбе көн
7) мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз. Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Күчте. Аллаһ Тәгалә рәхмәткә күмсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 99(117)x34x17.

10. Мөхәммәдсадыйк Галим улына куелган кабер ташы, 1900 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгааләә күллү
2) нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт руми
3) 1900 сәнә май 11 ндә Иске
4) Өҗемнең Мөхәммәдсадыйк
5) Галим углы 54
6) йәшендә пәнҗешәнбә көн
7) даре бәкайә рихләт кыйлды».

[92] Дәвамы сул ягында.
[93] Башы алгы ягында.

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ Тәгалә рәхмәт идүб җайын җәннәт кыйлгай иде амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәрбер
2) җан иясе үлемне татыячак. Милади
3) 1900 елның 11 маенда Иске
4) Өҗемнән Мөхәммәдсадыйк
5) Галим улы 54
6) яшендә пәнҗешәмбе көн
7) мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз. Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Аллаһ Тәгалә, рәхим кылып, урынын җәннәт итсә иде, амин».

Таш үлчәмнәре: 130х35х15.

11. Бибимәймүнә Садыйк кызына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) Иске Өҗем авылыйның Нигъмәт-
3) -җан Әйүб углының хәләле
4) Мәймүнә Садыйк кызы
5) 25 йәшендә даре фәнадан
6) даре бәкайә рихләт әйләде
7) Хода гарикы рәхмәт әйләйә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бибимәймүнә
2) тарих руми 1902 нче сәнә
3) дикәбр 8 нче көне мәдфүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәрбер җан иясе үлемне татыячак.
2) Иске Өҗем авылыннан Нигъмәт-
3) -җан Әюб улының хәләле –
4) Мәймүнә Садыйк кызы –
5) 25 яшендә фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга күчте.
7) Хода рәхмәткә күмсен».

Арткы ягы:
1) «Бибимәймүнә.
2) Милади 1902 ел
3) декабренең 8 нче көнендә җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 93х30х13.

12. Камилә Фәтхулла кызына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Иске Өҗем авылы
3) Мөхәммәдсадыйк бине Галим
4) җәмәгате Камилә бинте
5) Фәтхулла 1917 нче сәнә
6) март 14 ндә 72 йәшендә
7) дөнйадан үтде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Иске Өҗем авылыннан
3) Мөхәммәдсадыйк бине Галим
4) җәмәгате – Камилә бинте
5) Фәтхулла – 1917 елның
6) 14 мартында 72 яшендә
7) дөньядан үтте».

Таш үлчәмнәре: 104(118)х34х12.

13. Фәрвизә Әхмәд кызына куелган кабер ташы, 1924 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иске Өҗемнең
2) Фәрвизә Әхмәд кызы
3) Габделкадыйр җәмәгате
4) 1924 нче сәнә 24 ийүлдә
5) 65 йәшендә даре фәнадан
6) даре бәкайә рихләт әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Иске Өҗемнән
2) Фәрвизә Әхмәд кызы –
3) Габделкадыйр җәмәгате –
4) 1924 елның 24 июлендә
5) 65 яшендә фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 80(90)х28х8.

14. Гайшә Сәйфеддин кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Тарих миладиййә илә
2) 1910 нчы март 23 нче
3) көне Гайшә Сәйф-
4) -еддин кызы 60 йәшендә
5) даре фәнадан даре бәкайә
6) күчде Аллаһ рәхмәт әйләйә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Гайшә
2) Гыйльфан җәмәгате
3) углы Дәүләтгәрәй
4) бина кылдырды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Милади белән
2) 1910 [ел] мартының 23 нче
3) көнендә Гайшә Сәйф-
4) -еддин кызы 60 яшендә
5) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
6) күчте. Аллаһ рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Гайшә
2) Гыйльфан җәмәгате.
3) Улы Дәүләтгәрәй
4) куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 74(87)x31x10.

15. Гыйльфан Бикчәнтәй улына куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Тарих миладиййә илән
2) 1893 нче сәнә дикәбр 15 нче
3) көне Гыйльфан Бикчәнтәй
4) углы 60 йәшендә җан
5) тәслим әйләде Аллаһ рәхмәт
6) әйләйә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ-
2) -ил-гаффәәр
3) Иске Өҗем авылыйның
4) Гыйльфан бине Бикчәнтәй».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Милади белән
2) 1893 ел декабренең 15 нче
3) көнендә Гыйльфан Бикчәнтәй
4) улы 60 яшендә җан
5) тәслим кылды. Аллаһ рәхим
6) кылсын».

Арткы ягы:
1) «Хөкем Кичерүче
2) Аллаһта.
3) Иске Өҗем авылыннан
4) Гыйльфан бине Бикчәнтәй».

Таш үлчәмнәре: 74(85)x30x10.

16. Әюб Исмәгыйль улына куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әйүб
2) бине Исмәгыйль
3) 1926 нчы сәнә април
4) 15 ндә 90 йәшендә
5) вафат иннәә лилләәһи
6) вә иннәә иләйһи рааҗигуун
7) ләһүр-рахмәтү вәл-гуфраан».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әйүб
2) Иске Өҗем авылында
3) дәүләт ийәсе
4) картымыз иде
5) углы Нигъмәтҗан
6) бина кыйлдырды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Әюб
2) бине Исмәгыйль
3) 1926 елның 15
4) апрелендә 90 яшендә
5) вафат. Чынлыкта, без Аллаһныкы
6) һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз.
7) Анда [Аллаһта] рәхмәт һәм кичерү».

Арткы ягы:
1) «Әюб
2) Иске Өҗем авылында
3) дәүләт иясе [булган]
4) картыбыз иде.
5) Улы Нигъмәтҗан
6) куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 96x29x9.

17. Әсма Вәлид кызына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ

2) Әсма Вәлид кызы
3) 1902 нчы сәнә март 11 нче көне
4) 70 йәшендә җан тәслим
5) әйләде Әйүб хәләле».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Әсма Вәлид кызы
3) 1902 ел мартының 11 нче көнендә
4) 70 яшендә җан тәслим
5) кылды. Әюб хәләле».

Таш үлчәмнәре: 77x31x14.

18. Исмәгыйль Исхак Сиражеддин улының улына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Дийәләр кани атамыз дәхи сүвеклү анамыз атасыз атасыз без...
2) бу кабер сахибе
3) Исмәгыйль
4) атасы Төрекләр авылыйның Исхак
5) Сиражеддин углы 1907 нче
6) йылда ийүннең 3 нче көнендә
7) Иске Өҗем авылында тугды
8) һәм вафат итде шәфәгатьче».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Әйтәләр: «Кайда атабыз, шулай ук сөекле анабыз, атасыз-атасыз без...».
2) Бу кабер иясе
3) Исмәгыйль
4) (атасы Төрекләр авылыннан Исхак
5) Сиражеддин улы) 1907
6) ел июненең 3 нче көнендә
7) Иске Өҗем авылында туды
8) һәм вафат булды. Шәфәгатьче [булсын]».

Таш үлчәмнәре: 92x31x13.

19. Зөләйха Сәйфулла кызына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иске Өҗемнең
2) Габделмәҗид хәләле
3) Зөләйха Сәйфулла кызы
4) 1914 нче сәнә март 2 нче
5) көне 78 йәшендә җан
6) тәслим әйләде Аллаһ
7) рәхмәт әйләгәй иде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Иске Өҗемнән
2) Габделмәҗид хәләле –
3) Зөләйха Сәйфулла кызы –
4) 1914 ел мартының 2 нче
5) көнендә 78 яшендә җан
6) тәслим кылды. Аллаһ
7) рәхим кылса иде».

Таш үлчәмнәре: 86(93)x29x10.

20. Хаҗиәхмәд Галиәкбәр улына куелган кабер ташы, 1900 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Буны йазмакдан морадым догадыр бу көн бәнга йарин сәнгадыр
2) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
3) Иске Өҗем авылы Хаҗиәхмәд Гали-
4) -әкбәр углы 48 йәшендә даре фәна-
5) -дан даре бәкайә рихләт әйләде
6) Хода гарикы рәхмәт әйләгәй иде
7) 1900 нче йылда гыйнвар 27 сенд
8) урынын җәннәт әйләсүн амин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бине Галиәкбәр бине Бикчәнтәй әл-Өҗеми[94]
2) Хаҗиәхмәд[95]
3) бу дөнйаның гыйззе вә җаһы гыйшнуш пөр хыйал
4) күрмәдем бер гыйззәтен кем булмыйа ахыр зәвал
5) алың гыйбрәт бу дөнйаның фәсадындан
6) дәхи ата ананың вафатындан
7) углы Габделкәшшаф
8) бина кыйлдырды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Моны язудан морадым догадыр, бу көн миңа, иртәгә сиңадыр.
2) Һәр җан иясе үлемне татыячак.
3) Иске Өҗем авылыннан Хаҗиәхмәд Гали-
4) -әкбәр улы 48 яшендә
5) 1900 елның 27 гыйнварында
6) фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте.
7) Хода рәхмәткә күмсә иде,
8) урынын җәннәт итсен, амин».

[94] Башы икенче юлда.
[95] Дәвамы беренче юлда.

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Хаҗиәхмәд
2) бине Галиәкбәр бине Бикчәнтәй Өҗеми.
3) Бу дөньяның кадере һәм дәрәҗәсе – типтерү, хыял белән тулы.
4) Күрмәдем бер кадерен, ахырдан юкка чыгу булыр.
5) Ал гыйбрәт бу дөньяның бозыклыгыннан,
6) шулай ук ата-ананың вафат булуыннан.
7) Улы Габделкәшшаф
8) куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 98(120)х31х13.

Әлеге кабер иясенең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Хаҗиәхмәд бине Галиәкбәр бине Бикчәнтәй бине Бикбау бине Габдулла бине Аитмәмәт бине Уразбакты бине Шүдәк абыз бине Мостай бине Кодыш бине Багышкы бине Мәмәт[96].

21. Фәрхениса Сиддыйк Шәйхеморад улының кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Атасы Котаймас авылыйның Сиддыйк Шәйхеморад углы
2) бу кабер сахибе Фәрхенниса
3) 1907 нче йылда аугысның
4) 24 нче көнендә мәдфүн
5) каберен раудатүн мин рийәәд-
6) -ыйль-җинәән әйләгәй иде
7) әәмиин би-хүрмәти таа һәә вә йәә сиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Вәгазь натыйк кирәксә сәнга Коръән йитәр вәгазь самит кирәксә йәкфии ки табут кәфен».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) Иске Өҗем авылыйның
3) Хаҗиәхмәд Галиәкбәр углыйның
4) хәләле Фәрхенниса Сиддыйк
5) кызы 52 йәшендә даре
6) фәнадан даре бәкайә рихләт
7) итде рахмәтүллаahи рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер иясе Фәрхениса
2) (атасы Котаймас авылыннан Сиддыйк Шәйхеморад улы)
3) 1907 ел августының
4) 24 нче көнендә җирләнде.
5) [Аллаһ] каберен җәннәт бакчаларыннан
6) бер бакча итсә иде.
7) амин, «Та һә» һәм «Йә син» [сүрәләре] хөрмәтенә».

Уң ягы: «Вәгазь сөйләүче кирәк булса, сиңа Коръән җитәр. Телсез вәгазь кирәк булса, табут, кәфен җитәр».

Арткы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән
2) Иске Өҗем авылыннан
3) Хаҗиәхмәд Галиәкбәр улының
4) хәләле – Фәрхениса Сиддыйк
5) кызы – 52 яшендә фани
6) дөньядан мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аңа Аллаһның киң рәхмәте булсын».

Таш үлчәмнәре: 101х31х13.

22. Габделвәли Бикчәнтәй улына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи руми
2) 1899 сәнә март 15 дә
3) һиҗри 1316 сәнә Иске
4) Өҗемдә Габделвәли Бикчәнтәй
5) углы 82 йәшдә даре
6) бәкайә рихләт кылды».

Сул ягы (уеп язылган): «Тайййибәллаahү сәраahү вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта. Милади
2) 1899 елның 15 мартында,
3) һиҗри 1316 елда Иске
4) Өҗемдә Габделвәли Бикчәнтәй
5) улы 82 яшьтә мәңгелек
6) дөньяга күчте».

Сул ягы: «Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 95х33х17.

23. Бикмөхәммәд Хәбибулла улына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) 1905 нче сәнә дикәбр 7 нче

[96] Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / Төз. Р. Мәрданов, И. Һадиев. – Казан: Җыен, 2008. – Б. 218.

3) көне даре бәкайә рихләт әйләде
4) Бикмөхәммәд Хәбибулла углы
5) Хода гарикы рәхмәт әйләгәй иде
6) 72 йәшендә аз сүзле
7) гакыл сахибе адәм иде».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Углы
2) Габдеррахман бина кылды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) 1905 ел декабренең 7 нче
3) көнендә Бикмөхәммәд Хәбибулла улы
4) 72 йәшендә
5) мәңгелек дөньяга күчте.
6) Хода рәхмәткә күмсә иде.
7) Акыл иясе, аз сүзле адәм иде».

Арткы ягы:
1) «Улы
2) Габдрахман куйды».

Таш үлчәмнәре: 91(100)x32x11.

24. Хәдичә Шаһимәрдан кызына һәм Шаһимәрдан Бикмөхәммәд улына куелган кабер ташы, 1915 һәм 1933 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) 1915 нче сәнә април 29 нда
3) Хәдичә Шаһимәрдан
4) кызы 15 йәшендә
5) җан тәслим әйләде».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Шаһимәрдан
2) Бикмөхәммәд углы 1933 нче
3) йылда үктәбр 7 ндә
4) 76 йәшендә
5) җан тәслим әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) 1915 елның 29 апрелендә
3) Хәдичә Шаһимәрдан
4) кызы 15 яшендә
5) җан тәслим кылды».

Арткы ягы:
1) «Шаһимәрдан
2) Бикмөхәммәд улы 1933
3) елның 7 октябрендә
4) 76 яшендә
5) җан тәслим кылды».

Таш үлчәмнәре: 71(77)x31x10.

25. Йосыф Сөләйман улына куелган кабер ташы, 1908 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгаалә күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) Йосыф Сөләйман углы
3) 1908 нче йылда фивал 9 нчы көне
4) 80 йәшендә даре фәнадан даре
5) бәкайә рихләт әйләде Хода
6) рәхмәт әйләгәй иде».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Йосыф Сөләйман бине
2) нәдер мәгърур улуб йөрмәк
3) йатур урының ләхед булса
4) нәдер җаваб сөаленә
5) Мөнкир Нәкир сөаль кыйлса».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
2) Йосыф Сөләйман улы
3) 1908 ел фев[р]аленең 9 нчы көнендә
4) 80 яшендә фани дөньядан мәңгелек
5) дөньяга күчте. Хода
6) рәхим кылса иде».

Арткы ягы:
1) «Йосыф бине Сөләйман.
2) Нәрсәгә кирәк горур булып йөрү,
3) Ятар урының ләхет булса,
4) Нинди булыр җавап соравына,
5) Мөнкир, Нәкир сорау бирсә».

Таш үлчәмнәре: 71x29x8.

26. Бибилатыйфа Габделвәли хатыны-на куелган кабер ташы, 1884 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Иске Өҗем авылыйның
3) Габделвәли Бикчәнтәй
4) углыйның җәмәгате
5) Бибилатыйфа 1884 нче йылда
6) даре фәнадан даре
7) бәкайә рихләт әйләде
8) 60 йәшдә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Иске Өҗем авылыннан
3) Габделвәли Бикчәнтәй
4) улыйның җәмәгате
5) Бибилатыйфа 1884 елда

6) 60 яшьтә
7) фани дөньядан мәңгелек
8) дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 96(106)х31х12.

27. Галиәкбәр Бикчәнтәй Бикбау улының улына куелган кабер ташы, 1882 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Галиәкбәр
2) атасы Иске Өҗем авылыйның
3) Бикчәнтәй Бикбау углы
4) 1882 нче сәнә април 3 нче көне
5) 72 йәшендә даре фәнадан даре
6) бәкайә рихләт итде Хода
7) рәхмәт әйләгәй иде».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Габделкәшшаф
2) бине Хаҗиәхмәд бине
3) Бикчәнтәй бине Бикбау
4) бина кыйлдырды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Галиәкбәр
2) (атасы Иске Өҗем авылыннан
3) Бикчәнтәй Бикбау улы)
4) 1882 ел апреленең 3 нче көнендә
5) 72 яшендә фани дөньядан мәңгелек
6) дөньяга күчте. Хода
7) рәхим кылса иде».

Арткы ягы:
1) «Габделкәшшаф
2) бине Хаҗиәхмәд бине
3) Бикчәнтәй бине Бикбау
4) куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 90(107)х30х13.

Әлеге кабер иясенең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Галиәкбәр бине Бикчәнтәй бине Бикбау бине Габдулла бине Аитмәмәт бине Уразбакты бине Шүдәк абыз бине Мостай бине Кодыш бине Багышкы бине Мәмәт[97].

28. Хәбибулла Гобәйдулла улына куелган кабер ташы, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иске Өҗем авылыйның
2) Хәбибулла Гобәйдулла
3) углы 60 йәшендә
4) даре фәнадан даре бәкага
5) рихләт итде Аллаһ
6) рәхмәт әйләсүн».

Арткы ягы (уеп язылган): «Йаздыргучы Һидәйәтулла».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Иске Өҗем авылыннан
2) Хәбибулла Гобәйдулла
3) улы 60 яшендә
4) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
5) күчте. Аллаһ
6) рәхим кылсын».

Арткы ягы: «Яздыручы: Һидәятулла».

Таш үлчәмнәре: 64х33х9.

29. Хаҗивафа Габделмәннаф кызына куелган кабер ташы, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Котаймас авылыйның
2) Хаҗивафа Габделмәннаф
3) кызы 57 йәшендә
4) даре фәнадан даре бәкага
5) рихләт итде Аллаһ
6) рәхмәт әйләсүн».

Арткы ягы (уеп язылган): «Йаздыргучы Һидәйәтулла».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Котаймас авылыннан
2) Хаҗивафа Габделмәннаф
3) кызы 57 яшендә
4) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
5) күчте. Аллаһ
6) рәхим кылсын».

Арткы ягы: «Яздыручы: Һидәятулла».

Таш үлчәмнәре: 70х33х10.

30. Сафиулла Гобәйдулла улына һәм аның хатыны Бибихәнифәгә куелган кабер ташы, 1883 һәм 1908 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабер сахибе Сафийулла
2) атасы Иске Өҗем авылыйның Гобәйдулла
3) 1883 нче сәнә синтәбр 24 нче көне
4) 60 йәшендә даре фәнадан даре

[97] Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / Төз. Р. Мәрданов, И. Һадиев. – Казан: Җыен, 2008. – Б. 218.

5) бәкайә рихләт итде Хода рәхмәт әйләгәй
6) иде рахмәтүллаahи рахмәтән вәәсигаh».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабер сахибе Бибихәнифә
2) Иске Өҗем авылыйның Сафийулла
3) Гобәйдулла углының җәмәгате
4) 1908 нче сәнә синтәбр 24 нче көне
5) 80 йәшендә даре фәнадан даре бәкайә
6) рихләт итде Аллаh Тәгалә рәхмәт
7) әйләгәй иде рахмәтүллаahи рахмәтән вәәсигаh
8) Зиннәтулла бина кылдырды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер иясе Сафиулла
2) (атасы Иске Өҗем авылыннан Гобәйдулла)
3) 1883 ел сентябренең 24 нче көнендә
4) 60 яшендә фани дөньядан мәңгелек
5) дөньяга күчте. Хода рәхим кылса
6) иде. Аңа Аллаhның киң рәхмәте булсын».

Арткы ягы:
1) «Бу кабер иясе Бибихәнифә
2) (Иске Өҗем авылыннан Сафиулла
3) Гобәйдулла улының җәмәгате)
4) 1908 ел ел сентябренең 24 нче көнендә
5) 80 яшендә фани дөньядан мәңгелек дөньяга
6) күчте. Аллаh Тәгалә рәхим
7) кылса иде. Аңа Аллаhның киң рәхмәте булсын.
8) Зиннәтулла куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 94x31x14.

31. Мөхәммәдвәли Динмөхәммәд улына һәм Фәрхенур Гобәйдулла кызына куелган кабер ташы, 1865 һәм 1892 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-халләәкуль-бәәкыый
2) 1865 нче йыл 9 нчы
3) фибралда Казан гу-
4) -бирнасы Чар
5) өйәзе Иске
6) Өҗем авылыйның
7) Мөхәммәдвәли Динмөхәммәд
8) углы 59 йәшдә
9) дарел-бәкага
10) рихләт итде
11) Аллаh рәхмәт әйлә-
12) -сен амин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1892 нче йыл 6 нчы
2) априлдә Фәрхенур
3) Гобәйдулла кызы 87
4) йәшендә вафат
5) Мөхәммәдвәли җәмәгате».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаh] – Бар итүче, Мәңге.
2) 1865 елның 9
3) февралендә Казан гу-
4) -бернасы Чар
5) өязе Иске
6) Өҗем авылыннан
7) Мөхәммәдвәли Динмөхәммәд
8) улы 59 яшьтә
9) мәңгелек дөньяга
10) күчте.
11) Аллаh рәхим кыл-
12) -сын, амин».

Арткы ягы:
1) «1892 елның 6
2) апрелендә Фәрхенур
3) Гобәйдулла кызы –
4) Мөхәммәдвәли җәмәгате –
5) 87 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 86x32x7.

32. Габидә мулла Фазлулла кызына куелган кабер ташы, 1882 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) тарих румиййә илә 1882 нче
3) 14 нче үктәбр һижриййә илә
4) 1298 сәнә маһе зөлхиҗҗәдә
5) Габидә мулла Фазлулла кызы
6) Халид Әбүбәкер углының
7) зәүҗәсе 80 йәшдә кечатна»[98].

Уң ягы (калкытып язылган)[99]:
1) «... тәслим
2) ... әйләде
3) ... мәдфүн»[100].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади белән 1882 [елның]

[98] Дәвамы уң ягында.
[99] Ташның бер катламы тулысынча буе белән кисеп алынган, шуңа күрә бу яктагы текстка зыян килгән.
[100] Башы алгы ягында.

3) 14 октябрендә, һиҗри белән
4) 1298 елның зөлхиҗҗәсендә
5) Габидә мулла Фазлулла кызы –
6) Халид Әбүбәкер улының
7) хатыны – 80 яшьтә кече атна [пәнҗешәмбе]».

Уң ягы[101]:
1) «[Җан] тәслим
2) кылды.
3) ... җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 75(118)х32х11.

33. Гайнелхәят Мөхәммәдәмин кызына һәм мулла Хәбибулла мулла Фазлулла улына куелган кабер ташы, 1879 һәм 1883 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабер сахибе
2) Гайнелхәйәт Мөхәммәдәмин кызы
3) 1879 нчы йылда 6 нчы фибралда
4) даре фәнадан даре бәкайә рихләт
5) итде Хода рәхмәт әйләсүн».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) 1883 нче йылда 24 нче
3) ийүндә 70 йәшендә галәме фәна-
4) -дан галәме бәкайә рихләт әйләде
5) үстәәзүнәә вә үстәәзүл-күлли
6) мулла Хәбибулла бине мулла Фазлулла
7) рахмәтүллаәһи рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер иясе
2) Гайнелхәят Мөхәммәдәмин кызы
3) 1879 елның 6 февралендә
4) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
5) күчте. Хода рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) 1883 елның 24
3) июнендә 70 яшендә фани галәм-
4) -нән мәңгелек галәмгә
5) безнең остазыбыз һәм бөтен кешеләр остазы
6) мулла Хәбибулла бине мулла Фазлулла
7) Аңа Аллаһның киң рәхмәте булсын».

Таш үлчәмнәре: 84(97)х33х14.

Мулла Хәбибулланың фәнгә билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Хәбибулла бине Фазлулла бине Нигъмәтулла бине Бәшир бине Габдерәхим бине Уразмөхәммәд[102].

34. Бибилатыйфа мулла Фазылҗан кызына һәм Әсма Таҗеддин кызына куелган кабер ташы, 1890 һәм 1900 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) 1890 нчы сәнә майда даре
3) бәкайә рихләт әйләде зәүҗәи
4) Сабиржан бине Мөхәммәд-
5) -жан Бибилатыйфа бинте әл-хажҗе
6) мулла Фазылҗан Рәхмәти
7) 26 йәшендә Аллаһ рәхмәт кылсун».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Лилләәһил-фәәтихәһ
2) Әсма Таҗеддин кызы
3) 1900 нчы сәнә 20 нче дикәбр
4) 60 йәшендә тәслиме рух
5) әйләде Аллаһ рәхмәт әйләйә
6) мулла Фазылҗан зәүҗәсе».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) 1890 елның маенда
3) Сабиржан бине Мөхәммәд-
4) -жан хатыны – Бибилатыйфа бинте хажи
5) мулла Фазылҗан Рәхмәти
6) 26 яшендә мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы.
2) Әсма Таҗеддин кызы –
3) мулла Фазылҗан хатыны –
4) 1900 елның 20 декабрендә
5) 60 яшендә рух [жан] тәслим
6) кылды. Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 80х32х15.

Әсманың ире һәм Латыйфаның атасы – мулла Фазылҗан бине Фазлулла бине Рәхмәтулла Буави – 1893 елның 15 ноябрендә Буада вафат.

[101] Ташның бер катламы тулысынча буе белән кисеп алынган, шуңа күрә бу яктагы текстка зыян килгән.

[102] Мәржани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 241–242.

35. Бибимаһруй мулла Фазылхәбир кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә руми
2) 1905 сәнә һиҗри 1323 сәнә Биби-
3) -маһруй Фазлылхәбир кызы
4) әл-хаҗҗе мулла Фазылҗан
5) бине мулла Фазлулла зәүҗәсе
6) 66 йәшдә бәкайә рихләт кылды
7) маһе рәҗәб 27 нче йәүмендә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бибимаһруй бинте мулла Фазлылхәбир
2) зәүҗәи мулла Фазылҗан бине мулла Фазлулла».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) 1905 елда, һиҗри 1323 ел
3) рәҗәбенең 27 нче көнендә Биби-
4) -маһруй Фазылхәбир кызы –
5) хаҗи мулла Фазылҗан
6) бине мулла Фазлулла хатыны –
7) 66 яшьтә мәңгелеккә күчте».

Арткы ягы:
1) «Бибимаһруй бинте мулла Фазлылхәбир –
2) мулла Фазылҗан бине мулла Фазлулла хатыны».

Таш үлчәмнәре: 95х36х11.

Бибимаһруйның ире – мулла Фазылҗан бине Фазлулла бине Рәхмәтулла Буави – 1893 елның 15 ноябрендә Буада вафат.

36. Мөәзин Юныс мулла Сәйфулла улына куелган кабер ташы, 1892 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһил-гаффәәр
2) Иске Өҗем авылында указной
3) мөәзин Йуныс мулла Сәйфулла
4) углы даре фанадан даре
5) бәкайә рихләт итде 12 нче
6) гыйнварда 1892 нче йылда
7) 75 йәшдә Хода рәхмәт әйләйә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бу фәнаның гыйззе вә җаһы гыйшнуш пөр хыйал күрмәдем бер
2) гыйззәтен кем булмыйа ахыр зәвал
3) мөәзин
4) Йуныс мулла Сәйфулла углы
5) 45 йыл биля тәхәллеф мөәзинлек ләвазимен
6) итде рахмәтүллаһи рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кичерүче Аллаһ хөкеме белән.
2) Иске Өҗем авылында указлы
3) мөәзин Юныс мулла Сәйфулла
4) улы 1892 елның 12 гыйнварында
5) 75 яшьтә фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга күчте.
7) Хода рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Бу фани дөньяның кадере һәм дәрәҗәсе – типтерү, хыял белән тулы. Күрмәдем бер
2) кадерен, ахырдан юкка чыгу булыр.
3) Мәәзин
4) Юныс мулла Сәйфулла улы
5) 45 ел калдырмыйча мөәзинлек вазыйфаларын
6) үтәде. Аңа Аллаһның киң рәхмәте булсын».

Таш үлчәмнәре: 86х34х11.

Әлеге кабер иясе, мөәзин буларак билгеле булса да, авылда икенче мулла вазыйфасын да башкарган. Аның 1851 елның 13 июлендә указ (указ номеры – №7546) алганлыгы билгеле.

37. Мулла Лотфулла дамелла Габделфаяз улына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) 1905 нче йылда 24 нче
3) ийүндә мулла Лотфулла да-
4) -мелла Габделфаййаз углы даре
5) фәнадан даре бәкайә рихләт
6) әйләде 87 йәшендә Хода
7) гарикы рәхмәт әйләгәй иде
8) 55 йыл имам булуб гомер кичерде».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һиҗрииййә иләи
2) 1323 нче сәнә 4 нче
3) җөмадиәл-әүвәл Иске
4) Өҗем авылында мәдфүн
5) углы Мөхәммәдфатих бина
6) кыйлдырды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) 1905 елның 24
3) июнендә мулла Лотфулла да-
4) -мелла Габделфаяз улы
5) 87 яшендә фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга күчте.
7) Ходa рәхмәткә күмсә иде.
8) 55 ел имам булып гомер кичерде».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри белән
2) 1323 елның 4
3) җөмадиәл-әүвәлендә Иске
4) Өҗем авылында җирләнде.
5) Улы Мөхәммәдфатих
6) куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 87x31x13.

Әлеге кабер иясенең фәнгә билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Лотфулла бине Габделфаяз бине Габделгазиз бине Гайсә[103]. Ул 1850 елның 23 октябрендә указ (указ номеры – №10817) алгач, Иске Өҗем авылына имам итеп билгеләнгән. Атасы чыгышы белән хәзерге Арча районы Яңа Кенәр авылыннан булып, Кышкар саласында имам хезмәтен үтәгән. Лотфулла хәзрәтнең бабасы да Кушлавыч авылында (хәзерге Арча районы) муллалык вазыйфасын башкарган[104].

38. Гайшә Корбангали кызына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Тарих миладиййә илән
2) 1911 нче сәнә 16 нчы ийүлдә
3) Гайшә Корбангали
4) кызы 85 йәшендә җан
5) тәслим әйләде Аллаһ рәхмәт әйләйә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Милади белән
2) 1911 елның 16 июлендә
3) Гайшә Корбангали
4) кызы 85 яшендә җан
5) тәслим кылды. Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 66x31x9.

39. Гыйсмәтулла Фәтхулла улына куелган кабер ташы, 1891 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Гыйсмәтулла
2) Фәтхулла углы 1891 нче сәнә
3) март 5 ндә 71 йәшендә
4) җан тәслим әйләде
5) Аллаһ рәхмәт әйләб
6) җәннәт илә мөшәррәф әйләйә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Гыйсмәтулла
2) Фәтхулла улы 1891 елның
3) 5 мартында 71 яшендә
4) җан тәслим кылды.
5) Аллаһ, рәхим кылып,
6) җәннәт белән хөрмәтләсен».

Таш үлчәмнәре: 70x29x8.

40. Фазылҗан Мозаффар улына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһил-Гаффәәр
2) Иске Өҗем авылыйның Фазылҗан
3) Мозаффар углы 1910 нчы сәнә
4) дикәбр 4 ндә 77 йәшендә
5) даре фәнадан даре бәкайә
6) рихләт әйләде Хода
7) гарикы рәхмәт әйләгәй иде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем кичерүче Аллаһта.
2) Иске Өҗем авылыннан Фазылҗан
3) Мозаффар улы 1910 елның
4) 4 декабрендә 77 яшендә
5) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
6) күчте. Хода
7) рәхмәткә күмсә иде».

Таш үлчәмнәре: 106(117)x36x11

[103] Мәржани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 287–288. Әлеге китапны хәзерге телгә күчерүче шәҗәрәсе китерелгән хәзрәтнең исемен ялгыш Латыйфулла дип биргән, оригналда исә Лотфулла дип язылган (кара: Мәржани Ш.Б. Әл-кыйсмес-сани мин мөстәфадел-әхбари фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Казан университеты тәбгыханәсе, 1900. – Б. 184).
[104] Шунда ук. – Б. 287.

41. Бибифатыйма Гобәйдулла кызына һәм Хәбибулла Моталлиб улына куелган кабер ташы, 1911 һәм 1915 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бибифатыйма
2) Гобәйдулла кызы
3) 1911 сәнә фиврал 12 сендә
4) 65 йәшендә вафат».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Хәбибулла
2) бине Моталлиб 1915 нче сәнә
3) 12 нче нуйәбрдә
4) 80 йәшендә вафат
5) рахимәһүллаah углы Сибгатулла йаздырды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бибифатыйма
2) Гобәйдулла кызы
3) 1911 елның 12 февралендә
4) 65 яшендә вафат».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Хәбибулла
2) бине Моталлиб 1915 елның
3) 12 ноябрендә
4) 80 яшендә вафат.
5) Аллаһ аны рәхим кылсын. Улы Сибгатулла яздырды».

Таш үлчәмнәре: 70x32x9.

42. Газизә Габделлатыйф кызына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Иске Өҗем авылы
3) Гыйсмәтулла җәмәгате
4) Газизә Габделлатыйф кызы
5) 1909 нчы йылда 27 нче
6) дикәбр 60 йәшендә даре
7) фәнадан даре бәкайә күчде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Иске Өҗем авылыннан
3) Гыйсмәтулла җәмәгате –
4) Газизә Габделлатыйф кызы –
5) 1909 елның 27
6) декабрендә 60 яшендә фани
7) дөньядан мәңгелек дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 92x30x11.

43. Фәриха Габденнасыйр кызына куелган кабер ташы, 1924 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иске Өҗемнең
2) Фәриха бинте Габденнасыйр
3) 1924 сәнә 5 аугыст
4) 78 йәшендә вафат
5) рахимәһәәллаah».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Иске Өҗемнән
2) Фәриха бинте Габденнасыйр
3) 1924 елның 5 августында
4) 78 яшендә вафат.
5) Аллаһ аны рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 56x29x7.

44. Нәҗмеддин Шәмседдин улына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Иске Өҗем авылыйның
3) Нәҗмеддин Шәмседдин
4) углы 1914 нче сәнә үктәбр
5) 4 нче көне 74 йәшендә
6) даре фәнадан даре бәкайә
7) рихләт әйләде Хода
8) рәхмәт әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Иске Өҗем авылыннан
3) Нәҗмеддин Шәмседдин
4) улы 1914 ел октябренең
5) 4 нче көнендә 74 яшендә
6) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
7) күчте. Хода
8) рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 101(111)x31x12.

45. Хуҗаәхмәд Сиддыйк улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-кабру гыйбраһ
2) Хуҗаәхмәд Сиддыйк
3) углы 1920 нче сәнә ийүн 8 нд
4) 60 йәшендә вафат.
5) Аллаһ рәхмәт әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер – гыйбрәт.
2) Хуҗаәхмәд Сиддыйк
3) улы 1920 елның 8 июненд[ә]
4) 60 яшендә вафат.
5) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 70х32х8.

46. Гатаулла Хәбибулла улына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иске Өҗем
2) Гатаулла бине
3) Хәбибулла 1921 сәнә
4) гыйнвар 11 нче
5) көне 67(?) йәшендә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әскәнәһүллааһү
2) фии җинәәнин
3) вә гафәра би-фәдълиһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Иске Өҗемнән
2) Гатаулла бине
3) Хәбибулла 1921 ел
4) гыйнварының 11 нче
5) көнендә 67(?) яшендә [вафат]».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ аны җәннәтләргә
2) кертсен
3) һәм рәхмәте белән кичерсен».

Таш үлчәмнәре: 68х25х8

47. Мөхсин(?) Габделҗәлил улына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иске Өҗем авылы
2) Мөхсин(?) Габделҗәлил углы
3) 1921 нче сәнә гыйнвар 12 нче көне
4) даре фәнадан даре бәкайә
5) рихләт әйләде нәүвәраллааһү кабраһ».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Мәрхүм
2) аз сүзле иде
3) 77 йәшендә вафат
4) Аллаһ рәхмәт әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Иске Өҗем авылыннан
2) Мөхсин(?) Габделҗәлил улы
3) 1921 ел гыйнварының 12 нче көнендә
4) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
5) күчте. Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Арткы ягы:
1) «Мәрхүм
2) аз сүзле иде,
3) 77 яшендә вафат.
4) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 70х32х7.

48. Сибгатулла Гобәйдулла улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Сибгатулла Гобәйдулла
2) углы 1920 нче йылда
3) синтәбр 25 ндә 67 йәшендә
4) җан тәслим әйләде.
5) Аллаһ рәхмәт әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Сибгатулла Гобәйдулла
2) улы 1920 елның
3) 25 сентябрендә 67 яшендә
4) җан тәслим кылды.
5) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 57(63)х27х10.

49. Габдуллажан Шәрифҗан улына куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) 1926 нче йыл ийүл
3) 26 нда 41 йәшендә
4) Габдуллажан Шәрифҗан
5) углы җан тәслим
6) әйләде рахимәһүллааһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) 1926 елның 26
3) июлендә 41 яшендә

4) Габдуллажан Шәрифҗан
5) улы җан тәслим
6) кылды. Аллаһ аны рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 86х31х10.

50. Мәгърифә Бикмөхәммәд кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) 1905 нче йыл гыйнвар
3) 30 нчы көне 33 йәшендә
4) Мәгърифә Бикмөхәммәд кызы
5) җан тәслим әйләде
6) рахимәһәәллаһү Тәгаалә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) 1905 ел гыйнварының
1) «Румиййә
2) сәнәи 1851 нче
3) йылда мартның
4) 3 ндә Шаһ-
5) -гали Әхмәд углы
6) вафат арка тарафыйда».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) ... мең дә ике йөз дә...
2) икенче ел рабигыль-ахиренең бишенче
3) көнендә Биккенә кызы Хәбибҗамал – Әхмәд
4) хәләле – кырык биш яшендә фани дөньядан
5) мәңгелек дөньяга күчте. [Аллаһ] аның каберен нурландырсын».

Сул ягы:
1) «Милади
2) 1851
3) елның 3
4) мартында Шаһ-
5) -гали Әхмәд улы
6) вафат. Арткы тарафта [җирләнгән]».

Таш үлчәмнәре: 124х45х23.

31. Биккенә Атнаш улына куелган кабер ташы, XIX гасыр.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
«...
1) йылда...
2) Биккенә Атнаш углы даре фәна-
3) -дин даре бәкайә күчте раүвәхәллаһү
4) руухаһү вә нәүвәра мәркадәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) ... елда
2) Биккенә Атнаш улы фани дөнья-
3) -дан мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһ аның рухына
4) тынычлык бирсен һәм каберен нурландырсын».

Таш үлчәмнәре: 78х40х18.

32. Хөснеддин Биккенә улына куелган кабер ташы, 1858 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Һүвәл-хәййүл-ләзии ләә йәмүүт
2) саахиибү һәзәл-кабри саахиибүд-дәүләти вәл-хайраати
3) вәс-садәкаати мүтәвәффанил-мәрхүүмү Хөснеддин
4) бине Биккенә мәркадедүр вафат
5) 36 йәшендә 1858 йылда
6) румиййә иләнмаһе сәфәрнең 20
7) нче йәүмендә синтәбрнең 22
8) нче көнендә фәл-мүлтәмәсү лиһәзәл-мәр
9) әл-фәәтихәтү вәл-ихъләәсъ».

Уң ягы (калкытып язылган): «Тәәриихү һиҗратин-нәбии гһм 1275 нчедә».

Сул ягы (калкытып язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран би-әмрии күнтү бил-әмси мислүкә гадән тәсыыйру мислии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Тере, Үлмәүче.
2) Бу кабер иясе – дәүләт һәм яхшылыклар
3) иясе, сәдакалар бирүче вафат булган рәхим кылынган Хөснеддин
4) бине Биккенә кабере.
5) 36 яшендә милади белән
6) 1858 ел сентябренең 22
7) нче көнендә, сәфәр аеның 20
8) нче көнендә вафат. Мәр[хүм] өчен «Фатиха» һәм «Ихлас»
9) сүрәләрен уку сорала».

Уң ягы: «Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) һиҗрәте [Мәккәдән Мәдинәгә күченүеннән саналган ел исәбе] белән 1275 [елда вафат]».

Сул ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерләүче, кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Таш үлчәмнәре: 130х37х19.

33. Шаһиәхмәд Габденнасыйр улына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Шаһиәхмәд Габд-
3) -еннасыйр углы
4) миладиййә илә 1914 нче
5) йыл 4 нче ийүлдә
6) һиҗриййә илә 1331 сәнә
7) 62 йәшендә вафат
8) Хода гарикы рәхмәт әйләсүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Бәне күр бәне күр дә гүр йарагын кыйла күр»[262].

Сул ягы (уеп язылган): «Үтте дәүран кичде сәйран бәне күр»[263].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Шаһиәхмәд Габд-
3) -еннасыйр улы
4) милади белән 1914
5) елның 4 июлендә,
6) һиҗри белән 1331 елда
7) 62 яшендә вафат.
8) Хода рәхмәткә күмсен».

Уң ягы: «Мине күр дә гүр өчен кирәк-ярагыңны күр».

Сул ягы: «Үтте дәвер, бетте күңел ачу, мине күр».

Таш үлчәмнәре: 78х32х10.

34. Гамбәр Биккенә кызына куелган кабер ташы, 1867 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-хаккуль-бәәкыый
2) саахибәтү һәзәл-кабри мәрхүмә
3) Ганбәр Биккенә кызы Сабит җәмәгате
4) 1867 нче йылда
5) гыйнварның 27 нче көнендә
6) 70 йәшдә вафат Аллаһ
7) рәхмәт әйләсүн амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр»[264].

Сул ягы (уеп язылган): «Бу көн бәнга икән йарин сәнгадыр»[265].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Хак, Мәңге.
2) Бу кабер иясе мәрхүмә
3) Гамбәр Биккенә кызы – Сабит җәмәгате –
4) 1867 ел
5) гыйнварының 27 нче көнендә
6) 70 яшьтә вафат. Аллаһ
7) рәхим кылсын».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 86(100)х32х10.

35. Хәбибҗамал Халид кызына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-хаккуль-бәәкыый
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Хәбибҗамал Халид кызы
4) Мөхәммәҗән Вәлиша углы
5) әһлийәсе 1909 сәнә миладиййә
6) март 20 сендә 73
7) йәшендә мәдфүн нәүвәраллаһү
8) кабраһәә әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Хак, Мәңге.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Хәбибҗамал Халид кызы –
4) Мөхәммәҗән Вәлиша улының
5) хатыны – милади 1909 елның
6) 20 мартында 73
7) яшендә җирләнде. Аллаһ аның

[262] Башы сул ягында.
[263] Дәвамы уң ягында.
[264] Дәвамы сул ягында.
[265] Башы уң ягында.

8) каберен нурландырсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 85(100)х30х14.

36. Рабига Әхмәдша кызына куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабернең ийәсе
3) 2 нче мәхәлләнең Фәйзрахман
4) Биккениф җәмәгате
5) Рабига Әхмәдшаһ
6) кызы 38 йәшдә
7) вафат вакыты
8) тарих милади белә
9) 1926 нчы йыл»[266].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «6 нчы май һиҗри
2) тарих белә 1344 нче
3) йыл 23 нче шәүвәл
4) пәнҗешәнбә көн
5) Җәнабе Хак хәзрәте
6) каберине нурлы урыныйны
7) җәннәт кылсун амин»[267].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабернең иясе
3) 2 нче мәхәлләдән Фәйзрахман
4) Биккенев җәмәгате –
5) Рабига Әхмәдша
6) кызы – 38 яшьтә [вафат].
7) Вафат вакыты:
8) милади белән
9) 1926 елның».

Арткы ягы:
1) «6 мае, һиҗри
2) белән 1344
3) елның 23 шәүвәле,
4) пәнҗешәнбә көн.
5) Җәнабе Хак [Аллаһ]
6) каберен нурлы, урынын
7) җәннәт итсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 81х32х11.

37. Хәерниса Биккенә кызына куелган кабер ташы, 1927 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһәә илләәллааһ Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ
2) мәрхүмә Хәйренниса
3) Биккенә кызы Әхмәд-
4) -шаһ Фәтхулла у-
5) -глыйның җәмәгате вафат
6) 1927 нче милади
7) 21 нче нуйәбрдә 70
8) йәшендә рахимәһүллааһү
9) рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Таки рузи идә Аллаһ оҗмахы»[268].

Сул ягы (уеп язылган): «Даимән кыйлгыл гыйбадәт әй әхый»[269].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
2) мәрхүмә Хәерниса
3) Биккенә кызы – Әхмәд-
4) -ша Фәтхулла у-
5) -лының җәмәгате –
6) милади 1927 [елның]
7) 21 ноябрендә 70
8) яшендә вафат. Аллаһ аны киң рәхмәте
9) белән рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Аллаһ оҗмах бирсен өчен».

Сул ягы: «Даими гыйбадәт кыл, әй, минем кардәшем».

Таш үлчәмнәре: 101х35х9.

38. Бибигазизә Габделмәҗид кызына куелган кабер ташы, 1897 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) мәрхүмә Бибигазизә
3) Габделмәҗид кызы
4) һиҗриййә 1315 нче йылда
5) румиййә 1897 нче йылда
6) 17 нче дикәбрдә

[266] Дәвамы арткы ягында.
[267] Башы алгы ягында.
[268] Дәвамы сул ягында.
[269] Башы уң ягында.

7) 58 йәшендә
8) Сабиржан зәүҗәсе».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр»[270].

Сул ягы (уеп язылган): «Бу көн бәндә икән йарин сәңадыр»[271].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Мәрхүмә Бибигазизә
3) Габделмәҗид кызы –
4) Сабиржан хатыны –
5) һиҗри 1315 елда,
6) милади 1897 елның
7) 17 декабрендә
8) 58 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 85x31x11.

39. Сабиржан Биккенә улына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Сабиржан Биккенә углы
4) 1916 сәнә миладиййә май
5) 29 нда 75 йәшендә
6) вафат итде рахим-
7) -әллааһү рахмәтән вәәсигаһ
8) әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран фии әмрии»[272].

Сул ягы (уеп язылган): «Әмсин күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии»[273].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Сабиржан Биккенә улы
4) милади 1916 елның 29
5) маенда 75 яшендә
6) вафат булды Аллаһ
7) аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын,
8) амин».

Уң ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерләүче».

Сул ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Таш үлчәмнәре: 113x33x14.

40. Сабит Баязид улына куелган кабер ташы, 1877 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Сабит Байазид углы
4) румиййә илә 1877 нче
5) йылда 6 нчы иййүндә 70
6) йәшендә вафат Аллаһ рәхмәт
7) әйләсүн амин».

Уң ягы (калкытып язылган): «Күрүб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Сул ягы (калкытып язылган): «Дога берлә кыйлынгыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Сабит Баязид улы
4) милади белән 1877
5) елның 6 июнендә 70
6) яшендә вафат. Аллаһ рәхим
7) кылсын, амин».

Уң ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Сул ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 81(92)x32x14.

[270] Дәвамы сул ягында.
[271] Башы уң ягында.
[272] Дәвамы сул ягында.
[273] Башы уң ягында.

41. Габделкадыйр Муса улына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаahү Тәгааләә
2) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
3) бу кабер сахибе Габделкадыйр
4) Муса углы 1906 нчы
5) сәнәи миладиййә 17 нче дикәбр
6) 80 йәшендә вафат Аллаh рәхмәт
7) кыйлсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Әмсин күнтү мислүкә гадән әнтә тәсыйру мислии»[274].

Сул ягы (уеп язылган)[275]:
1) «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран фии әмрии
2) кәтәбәhәә мөәзин
3) Лотфулла»[276].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh Тәгалә әйтте:
2) «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
3) Бу кабер иясе Габделкадыйр
4) Муса улы милади
5) 1906 елның 17 декабрендә
6) 80 яшендә вафат. Аллаh рәхим
7) кылсын, амин».

Уң ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Сул ягы:
1) «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерләүче.
2) Моны язды: мөәзин
3) Лотфулла».

Таш үлчәмнәре: 95x38x13.

42. Гыйззәтулла Сабит улына куелган кабер ташы, 1889 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Инил-хүкмү илләә лилләәh
2) Гыйззәтулла
3) Сабит углы
4) 10 нчы ийүндә
5) 56 йәшендә
6) 1306 сәнәи һиҗриййә
7) 1889 сәнәи миладиййә
8) гарикы рәхмәт
9) улсун».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәрәм әйлә-
2) -б догад-
3) -а иденгез
4) йад тәсадды-
5) -клә кыйлунгыз
6) рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаhта гына.
2) Гыйззәтулла
3) Сабит улы
4) милади 1889 елның
5) 10 июнендә,
6) һиҗри 1306 елда
7) 56 яшендә [вафат].
8) Рәхмәткә
9) күмелсен».

Арткы ягы:
1) «Юмартлык кылы-
2) -п, догад-
3) -а искә
4) алыгыз, сәдака бирү
5) белән рухымны
6) шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 110x33x13.

43. Гаҗбикамал Төхфәтулла кызына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh
2) мәрхүмә Гаҗбикамал
3) Төхфәтулла кызы
4) Габделхаликъ җәмәгате
5) 1920 йыл синтәбр
6) 15 ндә 88 йәшдә
7) вафат Аллаh рәхмәт»[277].

Уң ягы (уеп язылган): «Күллү мән галәйhәә фәән».

Сул ягы (уеп язылган): «Әйләсүн амин»[278].

[274] Башы сул ягының беренче юлында..
[275] Беренче юлы вертикаль, калган юллары горизонталь рәвештә язылган.
[276] Беренче юлының дәвамы уң ягында.
[277] Дәвамы сул ягында.
[278] Башы алгы ягында.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) мәрхүмә Гаҗбикамал
3) Төхфәтулла кызы –
4) Габделхаликъ җәмәгате –
5) 1920 елның 15
6) сентябрендә 88 яшьтә
7) вафат. Аллаһ рәхим».

Уң ягы: «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани».

Сул ягы: «Кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 77х35х10.

44. Габделхаликъ Сабит улына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Габделхаликъ Са-
3) -бит углы 1921 йылда
4) април 25 ндә
5) 85 йәшдә вафат
6) Аллаһ рәхмәтендә бу-
7) -лсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Габделхаликъ Са-
3) -бит улы 1921 елның
4) 25 апрелендә
5) 85 яшьтә вафат.
6) Аллаһ рәхмәтендә бу-
7) -лсын, амин».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Таш үлчәмнәре: 69х34х7.

45. Зәйнулла Габделмәҗид улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
2) Зәйнулла Габделмәҗид
3) углы 1920 нче йылда
4) үктәбр 14 нче көне
5) 85 йәшендә җан
6) тәслим әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Зәйнулла Габделмәҗид
3) улы 1920 ел
4) октябренең 14 нче көнендә
5) 85 яшендә җан
6) тәслим кылды».

Таш үлчәмнәре: 78х32х9.

46. Сафиулла Гыйззәтулла улы Госмановка куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
2) Сафийулла
3) Гыйззәтулла углы
4) Госманыф
5) 79 йәшендә
6) 1921 йылда март
7) 4 ндә вафат
8) Аллаһ рәхмәт әйләйә».

Уң ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллааһү мәркадәһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Гафәраллааһү зүнүүбәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Сафиулла
3) Гыйззәтулла улы
4) Госманов
5) 79 яшендә
6) 1921 елның 4
7) мартында вафат.
8) Аллаһ рәхим кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Сул ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын кичерсен».

Таш үлчәмнәре: 93х32х14.

47. Бибифаизә Гыйззәтулла кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибәтүл-мәркадил-мәрхүүмәти
3) Бибифаизә Гыйззәтулла
4) кызы Сафийулла Гыйззәтулла
5) углының зәүҗәсе
6) 1907 нче йылда 20 нче гыйнвар
7) 60 йәшендә даре бәкайә рихләт
8) әйләде рахимәһәәллааһү Тәгаалә
9) рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Кабер иясе рәхим кылынган
3) Бибифаизә Гыйззәтулла
4) кызы – Сафиулла Гыйззәтулла
5) улының хатыны –
6) 1907 елның 20 гыйнварында
7) 60 яшендә мәңгелек дөньяга
8) күчте. Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте
9) белән рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 89(97)х33х11.

Югары Көек авылы зираты

1. Сибгатулла Вәлиулла улына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Йугары Кийекнең
4) Сибгатулла Вәлийулла
5) углы вафат булды
6) 1921 нче йылда 17 нч
7) ийүлдә 72 нче
8) йәшендә Аллаһ-
9) -ның рәхмәтендә
10) булсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Югары Көектән
4) Сибгатулла Вәлиулла
5) улы
6) 1921 елның 17
7) июлендә 72 нче
8) яшендә вафат булды. Аллаһ-
9) -ның рәхмәтендә
10) булсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 100(116)х34х15.

2. Зөләйха Сөләйман кызына куелган кабер ташы, 1879 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Зөләйха Сөләйман
4) кызы Вәлийулла Байазид
5) углыйның әһлийәсе
6) 1879 нчы сәнә 2 нче ийүн
7) 65 йәшдә мәдфүнә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Зөләйха Сөләйман
4) кызы – Вәлиулла Баязид
5) улының хатыны
6) 1879 елның 2 июнендә
7) 65 яшьтә җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 97х30х12.

3. Вәлиулла Баязид улына куелган кабер ташы, 1866 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Вәлийулла Байазид
4) углы 1866 нчы сәнә
5) 17 нче аугыстда
6) 45 йәшендә вафат
7) Аллаһ рәхмәт әйләсүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Ән-нәдәәмәтү ләә түфиидү бәгъдәл-әҗәл».

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблә-әҗәл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Вәлиулла Баязид
4) улы 1866 елның
5) 17 августында
6) 45 яшендә вафат.
7) Аллаһ рәхим кылсын».

Уң ягы: «Әҗәл килгәч, тәүбә файда бирми».

Сул ягы: «Әй, кардәшем, әҗәл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит».

Таш үлчәмнәре: 95x29x13.

4. Шәмседдин Исхак улына куелган кабер ташы, 1862 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) бу кабер ийәсе Малый Кийүк
3) илинең мөтәвәффа мәрхүм
4) Шәмседдин Исхак
5) углы 27 йәшендә 1862 нче
6) йыл 13 нче дикәбрдә кабере
7) нурлы булсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Зүүруль-кубүүра фә-иннәһәә түзәккируль-мәүүт».

Сул ягы (уеп язылган): «Әл-мәүтү кәфәә лил-мәръи вәәгыйзаа кәтәбәһү имаме Казаклар».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе Малый Көек
3) иленнән вафат булучы мәрхүм
4) Шәмседдин Исхак
5) улы 27 яшендә 1862
6) елның 13 декабрендә [вафат яки җирләнде]. Кабере
7) нурлы булсын, амин».

Уң ягы: «Каберләрне зиярәт кылыгыз, чынлыкта, алар үлемне искә төшерә».

Сул ягы: «Кеше өчен үлем вәгазьче буларак җиткән. Моны язды: Казаклар [авылы] имамы».

Таш үлчәмнәре: 98x34x16.

5. Бибилатыйфа Салихҗан кызына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу кабер сахибәсе
3) мәрхүмә Бибилатыйфа
4) Салихҗан кызы
5) Йугары Кийек авылы-
6) -ның Сәмигулла
7) җәмәгате вафат булды
8) 1920 нче йылда».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «68 нче
2) йәшендә
3) Аллаһ Тәгаләнең
4) рәхмәтендә
5) булсун амин
6) мөэмин карендә-
7) -шләрдән дога кыйлма-
8) -кыныгызны үтенәмез».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе
3) мәрхүмә Бибилатыйфа
4) Салихҗан кызы –
5) Югары Көек авылын-
6) -нан Сәмигулла
7) җәмәгате –
8) 1920 елда вафат булды».

Арткы ягы:
1) «68 нче
2) яшендә [вафат].
3) Аллаһ Тәгаләнең
4) рәхмәтендә
5) булсын, амин.
6) Мөэмин карендә-
7) -шләрдән дога кылу-
8) -ыгызны үтенәбез».

Таш үлчәмнәре: 67x30x10.

6. Фәхрениса Шәмседдин кызына куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) бу каберә назилә мәрхүмә

3) Фәхренниса Шәмседдин
4) кызы Гатаулла Төхфәт-
5) -улла углыйның әһлийәсе
6) 1926 нчы сәнә 7 фиврал
7) 78 йәшендә мәдфүнә».

Уң ягы (уеп язылган): «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Сул ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлынгыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Фәхрениса Шәмседдин
4) кызы – Гатаулла Төхфәт-
5) -улла улының хатыны –
6) 1926 елның 7 февралендә
7) 78 яшендә җирләнде».

Уң ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Сул ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 75х31х10.

7. Габделхаликъ Габделвәли улына куелган кабер ташы, 1894 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу каберә назил мәрхүм
3) Габделхаликъ Габделвәли
4) углы 1894 сәнә 20 нч
5) аугыстда 62 йәшендә
6) вафат Аллаһ рәхмәт әйләсүн
7) амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлынгыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүм
3) Габделхаликъ Габделвәли
4) улы 1894 елның 20
5) августында 62 яшендә
6) вафат. Аллаһ рәхим кылсын,
7) амин».

Уң ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Таш үлчәмнәре: 80х31х12.

8.Фәхрениса Исмәгыйль кызына куелган кабер ташы, 1897 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-хәлләәкуль-бәәкыый
2) саахибәтү һәзәл-кабри мәрхүмә
3) Фәхренниса Исмәгыйль кызы
4) Хәлилулла әһлийәсе
5) 1897 нче йылда 1 нч
6) фивралда 42 йәшендә
7) мәдфүнә нәүвәраллаһү
8) кабраһәә әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Мәңге.
2) Бу кабер иясе мәрхүмә
3) Фәхрениса Исмәгыйль кызы –
4) Хәлилулла хатыны –
5) 1897 елның 1
6) февралендә 42 яшендә
7) җирләнде. Аллаһ аның
8) каберен нурландырсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 99х31х11.

9. Хәлилулла Хәбибулла улына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би- хүкмилләәһи Тәгаалә
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Хәлилулла Хәбибулла
4) углы 1904 нче сәнә
5) 25 нче ийүлдә
6) 62 йәшендә вафат Аллаһ
7) рәхмәт әйләсүн амин».

Уң ягы (уеп язылган)[279]:
1) «Дога берлә кыйлынгыз рухымы шад

[279] Беренче юлы вертикаль, калганнары диагональ рәвештә язылган.

2) кәтәбәһәә
3) мөәзине Үртәм
4) Лотфулла».

Сул ягы (уеп язылган): «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Хәлилулла Хәбибулла
4) улы 1904 елның
5) 25 июлендә
6) 62 яшендә вафат. Аллаһ
7) рәхим кылсын, амин».

Уң ягы:
1) «Дога белән рухымны шатландырыгыз.
2) Моны язды:
3) Үртәм [авылы] мөәзине
4) Лотфулла».

Сул ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Таш үлчәмнәре: 80x31x12.

10. Гыйнәятулла Гатаулла улына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгаалә
2) күллү нәфсиң-зәәъикатүл-мәүүт
3) саахибү һәзәл-кабри Гыйнәят-
4) -улла Гатаулла углы
5) румиййә илә 1903 нче йылда
6) агусның 14 нче көнендә
7) 29 йәшендә пәнҗешәнбә көн
8) дарел-бәкайә рихләт кыйлды
9) кабере мөнәүвәр улсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадур бу көн бәнгә икән йарун сәнгәдер».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте:
2) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
3) Бу кабер иясе Гыйнәят-
4) -улла Гатаулла улы
5) милади белән 1903 ел
6) августының 14 нче көнендә
7) 29 яшендә пәнҗешәмбе көн
8) мәңгелек дөньяга күчте.
9) Кабере нурлы булсын, амин».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 85(94)x35x11.

11. Мөхәммәдша Яһүдә улына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әгуузү билләәһи минәш-шәйтааниррәҗиим
2) бисмилләәһир-рахмәнир-рахиим
3) ләә иләәһә илләәллааһ Мүхәммәдүррасүүлүллааһ
4) әл-мәүүт әл-мәүүт күллү нәфсиң зәәъикат-
5) -үл-мәүүт 1909 нчы йылда 8 нч
6) априлдә 63 йәшендә
7) Мөхәммәдшаһ Йәһүдә углы
8) вафат булды Аллаһ рәхмәт
9) кыйлгай иде амин
10) күллү мән галәйһәә фәән».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер сахибе мәр-
3) -хүм Мөхәммәдша
4) Йәһүдә углы
5) әй мөэмин кардәш-
6) -ләр догадан ташлама-
7) -гызлар».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ләгънәт кылынган шайтаннан Аллаһка сыенам.
2) Шәфкатьле, рәхимле Аллаһ исеме белән.
3) Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
4) Үлем. Үлем. Һәр җан иясе үлемне
5) татыячак. 1909 елның 8
6) апрелендә 63 яшендә
7) Мөхәммәдша Яһүдә улы
8) вафат булды. Аллаһ рәхим
9) кылса иде, амин.
10) Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе: мәр-
3) -хүм Мөхәммәдша
4) Яһүдә улы.
5) Әй, мөэмин-кардәш-

6) -ләр, догадан ташлама-
7) -гыз».

Таш үлчәмнәре: 75х32х11.

12. Бибизөләйха Хисамеддин кызына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Лилләәһил-фәәтихәһ
2) дарел-фәнадин
3) дарел-бәкайә
4) рихләт әйләде
5) Бибизөләйха
6) Хисамеддин кызы
7) Сибгатулла(?) җәмәгате».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 1904 нҗе йылда
3) 1319 һиҗри
4) фибрал 20 ндә
5) рамазан 25 ндә
6) 44 йәшендә
7) вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы.
2) Бибизөләйха
3) Хисамеддин кызы –
4) Сибгатулла(?) җәмәгате –
5) фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга
7) күчте».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1904 елның
3) 20 февралендә,
4) һиҗри 1319 [елның]
5) 25 рамазанында
6) 44 яшендә
7) вафат».

Таш үлчәмнәре: 82х31х9.

13. Хәбибулла улына куелган кабер ташы, 1892 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкм-
2) -илләәһи Тәгаалә
3) ләә иләәһә илләәллааһ
4) Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ
5) бу кабер сахибе мәрхүм
6) ... Хәбибулла
7) углы 1892 нче йыл
8) майның 15 ндә»[280].

Уң ягы (уеп язылган): «Тәүбәдер җәннәтә кирәргә сәбәб».

Сул ягы (уеп язылган): «Тәүбәдер...[281] кыйлмага сәбәб».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «53 йәшендә
2) вафат әйләде
3) Аллаһның рәх-
4) -мәтендә булсын
5) амин»[282].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә
2) хөкеме белән.
3) Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк,
4) Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
5) Бу кабер иясе мәрхүм
6) ... Хәбибулла
7) улы 1892 елның
8) 15 маенда».

Уң ягы: «Тәүбәдер җәннәткә керергә сәбәп».

Сул ягы: «Тәүбәдер... кылуга сәбәп».

Арткы ягы:
1) «53 яшендә
2) вафат булды.
3) Аллаһның рәх-
4) -мәтендә булсын,
5) амин».

Таш үлчәмнәре: 65х27х8.

14. Хәнифә Шәһидулла кызына куелган кабер ташы, 1925 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу каберә назилә

[280] Дәвамы арткы ягында.
[281] Бу урыны уалган.
[282] Башы алгы ягында.

3) мәрхүм Хәнифә
4) Шәһидулла кызы
5) Латыйф җәмәгате вафат
6) булды 1925
7) 73 йәшдә».

Сул ягы (уеп язылган): «Агусның 11 ндә дога багышлагыз».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә иңүче
3) мәрхүм Хәнифә
4) Шәһидулла кызы –
5) Латыйф җәмәгате –
6) 1925 [елда]
7) 73 яшьтә вафат булды».

Сул ягы: «Августның 11 ндә [вафат]. Дога багышлагыз».

Таш үлчәмнәре: 61х29х6.

15. Лотфулла Вәлиулла улына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Лотфулла Вәлийулла
4) углы 1916 нчы йылда
5) ийүн 12 ндә 70 йәшдә
6) вафат рахимәллаһү рахмәтән
7) вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Таки рузи идә Аллаһ оҗмахы»[283].

Сул ягы (уеп язылган): «Даимән кыйлгыл гыйбадәт әй әхый»[284].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Лотфулла Вәлиулла
4) улы 1916 елның
5) 12 июнендә 70 яшьтә
6) вафат. Аллаһ киң рәхмәте белән
7) рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Аллаһ оҗмах бирсен өчен».

Сул ягы: «Даими гыйбадәт кыл, әй, минем кардәшем».

Таш үлчәмнәре: 83х32х10.

16. Фаизә Хәбибулла кызына куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер ийәсе Фаизә
3) Хәбибулла кызы
4) Лотфулла әһлийәсе
5) вафат булды 75 йәшдә
6) 1926 нчы йылда агусның 7».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе Фаизә
3) Хәбибулла кызы –
4) Лотфулла хатыны –
5) 75 яшьтә
6) 1926 елның 7 августында вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 61х36х11.

17. Әхмәҗән Гали улына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Әхмәҗән Гали углы
4) 1917 сәнә үктәбр 5 ндә
5) 1336 сәнәи һиҗрииййә мөхәррәм 2 ндә
6) 53 йәшдә вафат Аллаһ
7) рәхмәт әйләсүн
8) амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Гакыйбәт бер көн әҗәл әйләр галил»[285].

Сул ягы (уеп язылган): «Нә дәклү улса да гомерең тавил»[286].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм

[283] Дәвамы сул ягында.
[284] Башы уң ягында.
[285] Башы сул ягында.
[286] Дәвамы уң ягында.

3) Әхмәҗән Гали улы
4) 1917 елның 5 октябрендә,
5) һиҗри 1336 елның 2 мөхәррәмендә
6) 53 яшьтә вафат. Аллаһ
7) рәхим кылсын,
8) амин».

Уң ягы: «Ахырдан беркөн әҗәл хәлсез итәр».

Сул ягы: «Ни тиклем гомерең озын булса да».

Таш үлчәмнәре: 98х31х11.

18. Гайнекамал Гобәйдулла кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер сахибәсе
3) мәрхүмә Гайне-
4) -камал Гобәйдулла
5) кызы вафат бу-
6) -лды 1907 нче
7) йыл 25 нче агусда
8) 70 йәшендә
9) Аллаһ рәхмә-
10) -тендә булсын амин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Йугары Кө-
2) -йекнең Закир
3) җәмәгате».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе
3) мәрхүмә Гайне-
4) -камал Гобәйдулла
5) кызы
6) 1907
7) елның 25 августында
8) 70 яшендә вафат булды.
9) Аллаһ рәхмә-
10) -тендә булсын, амин».

Арткы ягы:
1) «Югары Кө-
2) -ектән Закир
3) җәмәгате».

Таш үлчәмнәре: 90(120)х30х15.

19. Вәлиулла Гобәйдулла улына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибү һәзәл-кабри
2) мәрхүм Вәлийулла Гобәйдулла
3) углы 1906 нчы йылда
4) 10 нчы аугусда 55 йәшдә
5) дарел-бәкайә рихләт
6) кыйлды рахимәһүллаһү
7) рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Сул ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлыңгыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер иясе
2) мәрхүм Вәлиулла Гобәйдулла
3) улы 1906 елның
4) 10 августында 55 яшьтә
5) мәңгелек дөньяга
6) күчте. Аллаһ аны киң рәхмәте
7) белән рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Сул ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 82х32х11.

20. Мәхубҗамал Әбүбәкер кызына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер сахибә-
3) -се Йугары
4) Кийек авылыйның
5) мәрхүмә
6) Мәхубҗамал
7) Әбүбәкер
8) кызы»[287].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Габделлатыйф
2) җәмәгате вафат

[287] Дәвамы арткы ягында.

3) булды 1918 нч
4) йылда гыйнварның
5) 10 нчы көнендә
6) 65 йәшдә Аллаһ-
7) -ның рәхмәтендә
8) булсун амин»[288].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер ия-
3) -се Югары
4) Көек авылыннан
5) мәрхүмә
6) Мәхубҗамал
7) Әбүбәкер
8) кызы –».

Арткы ягы:
1) «Габделлатыйф
2) җәмәгате –
3) 1918
4) ел гыйнварының
5) 10 нчы көнендә
6) 65 яшьтә вафат булды. Аллаһ-
7) -ның рәхмәтендә
8) булсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 70х26х9.

21. Мәфтуха Сабит кызына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Мәфтуха Сабит кызы
4) Габделхаликъ Габделвәли
5) углының җәмәгате 1911 сәнә
6) синтәбр 4 ндә 84 йәшдә
7) вафат рахимәллааһү рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Ән-нәдәәмәтү ләә түфиидү бәгъдәл-әҗәл».

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблә-әҗәл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүм
3) Мәфтуха Сабит кызы –
4) Габделхаликъ Габделвәли
5) улының җәмәгате – 1911 елның
6) 4 сентябрендә 84 яшьтә
7) вафат. Аллаһ киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Әҗәл килгәч, тәүбә файда бирми».

Сул ягы: «Әй, кардәшем, әҗәл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит».

Таш үлчәмнәре: 82х31х10.

22. Галәеддин Исмәгыйль улына куелган кабер ташы, XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә иллә-
2) -ллааһ Мүхәммәдүр-
3) расүүлүллааһ
4) бу кабер
5) Исмәгыйль
6) углы
7) Галәәддин
8) мәрхүм
9) 49 йәшдә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга
2) лаеклы зат юк, Мөхәммәд –
3) Аллаһның илчесе.
4) Бу кабер
5) Исмәгыйль
6) улы
7) Галәеддин
8) мәрхүм
9) 49 яшьтә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 63х24х9.

23. Низамеддин Сәгъдеддин улына куелган кабер ташы, 1933 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер сахибе
3) мәрхүм Низамеддин
4) Сәгъдеддин углы
5) 1933 нче йылда 11 нче
6) ийүндә вафат булды».

[288] Башы алгы ягында.

Сул ягы (уеп язылган): «Ләә иләәһә илләәллаah Мүхәммәдүр-расүүлүллаah».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе
3) мәрхүм Низамеддин
4) Сәгъдеддин улы
5) 1933 елның 11
6) июнендә вафат булды».

Сул ягы: «Аллаhтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаhның илчесе».

Таш үлчәмнәре: 50х26х13.

Әлеге кабер иясенең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Низамеддин бине Сәгъдеддин бине Вахид бине Гали бине Габидулла бине Морад бине Күбәк[289].

24. Мәйсәрә Мөслим кызына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу каберә назилә мәр-
3) -хүмә Мәйсәрә Мөслим
4) кызы Габдуллажан
5) Әхмәджан углының җәмә-
6) -гате вафат булды 1920
7) нче йылда 14 нче дикәбрдә
8) 60 йәшендә Аллаhның
9) рәхмәтендә булсын амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Үтте дәүран кичде сәйран мине күр».

Сул ягы (уеп язылган): «Мине күр дә гүр йарагын синдә кыл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh хөкеме белән.
2) Бу кабергә иңүче мәр-
3) -хүмә Мәйсәрә Мөслим
4) кызы – Габдуллажан
5) Әхмәджан улының җәмә-
6) -гате –1920
7) елның 14 декабрендә
8) 60 яшендә вафат булды. Аллаhның
9) рәхмәтендә булсын, амин».

Уң ягы: «Үтте дәвер, бетте күңел ачып йөрү, мине күр».

Сул ягы: «Мине күр дә гүр кирәк-ярагын син дә әзерлә».

Таш үлчәмнәре: 70х32х15.

25. Габделхаликъ Габделвәли улына куелган кабер ташы, 1894 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу каберә назил мәрхүм
3) Габделхаликъ Габделвәли
4) углы 1894 сәнә 20 нч
5) аугыстда 62 йәшендә
6) вафат Аллаh рәхмәт әйләсүн
7) амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлынгыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh хөкеме белән.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүм
3) Габделхаликъ Габделвәли
4) улы 1894 елның 20
5) августында 62 яшендә
6) вафат. Аллаh рәхим кылсын,
7) амин».

Уң ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Таш үлчәмнәре: 80х31х12.

Югары Сәрдә авылы зираты

1. Әхмәдулла Төхфәтулла улына куелган кабер ташы, 1934 ел.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмәә Тәгаалә

[289] Әхмәтҗанов М.И. Татар археографиясе. Милли-мәдәни мирас хәзинәләре системасына сәхифәләр. – Казан, 2011. – Б. 180.

2) сахиибүл-мәкаати
3) Төхфәтулла углы
4) Әхмәдулла 1934
5) йылда майда 74
6) йәшендә
7) даре бәка хләтә әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем [Аллаһ] Тәгаләдә.
2) Кабер иясе
3) Төхфәтулла улы
4) Әхмәдулла 1934
5) елның маенда 74
6) яшендә
7) мәңгелек дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 100(114)х38х20.

2. Камаледдин Шәмседдин улына куелган кабер ташы, 1930 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Туган
2) 1856
3) Камаледдин
4) Шәмседдин
5) углы вафат
6) йыл 1930».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Камаледдин
2) Шәмседдин
3) углы
4) 1856 [елда] туган,
5) 1930 елда
6) вафат».

Таш үлчәмнәре: 52х33х9.

3. Әүхәди Тимергали улына куелган кабер ташы, 1933 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Лилләәһил-фәәтихәһ
2) Әүхәди Тимергали
3) углы 60 йәшендә
4) ...3 сәнәдә 26 нчы
5) фивралда вафат
6) Аллаһ рәхмәт кыйлсун
7) йат әти син мәркадеңдә
8) кайгы гамьләр чикмичә
9) йук күрешмәк инде бер дә
10) йәүме мәхшәр җитмичә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы.
2) Әүхәди Тимергали
3) улы 60 яшендә
4) 1933 елның 26
5) февралендә вафат.
6) Аллаһ рәхим кылсын.
7) Ят, әти, син, каберeңдә
8) Кайгы-гамьнәр чикмичә,
9) Юк күрешү инде бер дә
10) Мәхшәр көне җитмичә».

Таш үлчәмнәре: 99х33х18.

4. Мулла Габделхәлим мулла Зөбәер улына куелган кабер ташы, 1894 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Имам вә мөдәррис Габделхәлим мулла
2) Зөбәйер углы Йукары Сәрдә
3) карйәсенең 1312 сәнә һиҗриййә
4) сәфәрнең 9 нҗы йәүмендә
5) даре бәкайә рихләт әйләде
6) рахимәһүллаһү Тәгаалә әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Югары Сәрдә авылыннан
2) имам һәм мөдәррис Габделхәлим мулла
3) Зөбәер улы һиҗри 1312 ел
4) сәфәренең 9 нчы көнендә
5) мәңгелек дөньяга күчте.
6) Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 85х35х18.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 11 б. №98.

5. Бибиәсма Шакир кызына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) саахибәтүл-мәркади Бибиәсма
3) Шакир кызы Гыйльман
4) зәүҗәсе 1904 нче йылда

5) нуйәбр 24 нче көнендә
6) 53 йәшендә даре бәкайә рихләт
7) әйләде рахимәһәллаһү
8) Тәгаалә рахмәтән вәәсигаһ
9) әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) кабер иясе Бибиәсма
3) Шакир кызы – Гыйльман
4) хатыны – 1904 ел
5) ноябренең 24 нче көнендә
6) 53 яшендә мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ Тәгалә аны киң
8) рәхмәте белән рәхим кылсын,
9) амин».

Таш үлчәмнәре: 99(112)x36x18.

6. Гөлҗамал Шакир кызына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибәтүл-мәркади
2) Гөлҗамал Шакир
3) кызы 53 йәшендә
4) 1909 сәнә нуйәбр 2 ндә
5) дәфен иделде Аллаһ
6) Тәгалә гөнаһларыйны
7) ...».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдин морадум бер догадур».

Сул ягы (уеп язылган): «Бу көн бәңа икән йарин сәңадур».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер иясе
2) Гөлҗамал Шакир
3) кызы 53 яшендә
4) 1909 елның 2 ноябрендә
5) җирләнде. Аллаһ
6) Тәгалә гөнаһларын
7) [гафу итсен]».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 87x36x15.

7. Җәмилә Мөхәммәдгали кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун
2) изәә тәхәййәртүм фил-үмүүри фәстәгыыйнүү
3) мин әһлил-кубүүр саахиб-
4) -үл-мәркади Җәмилә Мөхәммәдгали
5) кызы вафат 1905 нҗе
6) йылда 72 нче йәшендә
7) Олуг Сәрдә мәкъбәрәсендә
8) мәдфүн Аллаһ Тәгалә рәхмәт
9) әйләсүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм идүб дога илә идеңез йад».

Сул ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә идеңез рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз.
2) Әгәр [бу] эшләрдә аптырашта калсагыз, кабер
3) әһелләреннән сорагыз. Кабер
4) иясе Җәмилә Мөхәммәдгали
5) кызы вафат, 1905
6) елда 72 нче яшендә
7) Олы Сәрдә зиратында
8) җирләнде. Аллаһ Тәгалә рәхим
9) кылсын».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Сул ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 88x27x13.

8. Миңлебай Гайнулла улына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи
2) саахибүл-мәркади
3) Миңлебай Гайнулла
4) углы 71 йәшендә
5) 1916 нчы сәнәдә дикәбрнең
6) 1 нче көнендә даре бәкайә
7) рихләт әйләде
8) рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) кабер иясе
3) Миңлебай Гайнулла
4) улы 71 яшендә
5) 1916 ел декабренең
6) 1 нче көнендә мәңгелек дөньяга
7) күчте.
8) Киң рәхмәте белән [Аллаһ аны рәхим кылсын]».

Таш үлчәмнәре: 95x32x12.

9. Фатиха Әхмәҗән кызына куелган кабер ташы, 1917 (1919) ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Фатиха
2) Әхмәҗән
3) кызы
4) 73 йәшендә
5) 1917 йылда 17 нче
6) дикәбрдә вафат».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Фатиха
2) Әхмәҗән
3) кызы
4) 73 йәшендә
5) 1919, майда
6) Фатиха
7) Әхмәҗән кызы
8) Аллаһ рәхмәт кыйлсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Фатиха
2) Әхмәҗән
3) кызы
4) 73 яшендә
5) 1917 елның 17
6) декабрендә вафат».

Арткы ягы:
1) «Фатиха
2) Әхмәҗән
3) кызы
4) 73 яшендә
5) 1919 елның маенда вафат.
6) Фатиха
7) Әхмәҗән кызы.
8) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 71x31x10.

10. Тимергали Мәсгудь улына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Тимергали
2) Мәсгудь углы
3) 77 йәшендә
4) 1917 йылда 17 дә
5) дикәбрдә вафат
6) Аллаһ рәхмәт кыйлсун».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Тимергали
2) Мәсгудь улы
3) 77 йәшендә
4) в. 1917, 17 / XII
5) Тимергали
6) Мәсгудь улы
7) Аллаһ рәхмәт кыйлсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Тимергали
2) Мәсгудь улы
3) 77 яшендә
4) 1917 елның 17
5) декабрендә вафат.
6) Аллаһ рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Тимергали
2) Мәсгудь улы
3) 77 яшендә
4) 1917 елның 17 декабрендә вафат.
5) Тимергали
6) Мәсгудь улы.
7) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 65x31x11.

Югары Сәрдә авылы янындагы (көньягындагы) аерым каберлек

1. Мамай Мөлкәман улына куелган кабер ташы, 1538–1539 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллааһү Тәбәәракә вә Тәгааләә
2) күллү мән галәйһәә фәән вә йәбкаа вәҗһү
3) Раббикә зүүл-җәләәли вәл-икраам
4) тарих тукуз йөз кырык бишдә

5) Мөлкәман углы Мамай газатка
6) барганда кяфер кулындин шәһид булды».

Уң ягы (калкытып язылган): «Кааләл-нәбии галәйһис-сәләәм әд-дүнйәә мәзрагатүл-әәхыйрah».

Сул ягы (калкытып язылган): «Кааләл-нәбии галәйһис-сәләәм әд-дүнйәә сәәгатүн фәҗгальһәә таагаһ».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «...
2) ... Мөлкәман к...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә әйтте:
2) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани, фәкать Раббыңның
3) Олуглык һәм хөрмәткә ия булган йөзе генә калачак.
4) Тугыз йөз кырык бишенче [елда]
5) Мөлкәман улы Мамай сугышка
6) барганда кяфер кулыннан шәһид булды».

Уң ягы: «Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) әйтте: «Дөнья – ахирәт басуы»«.

Сул ягы: «Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) әйтте: «Дөнья бер сәгатьлек, аны [Аллаһка] итагать белән үткәр».

Арткы ягы:
1) «...
2) ... Мөлкәман к...».

Таш үлчәмнәре: 137x53x25.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 11 б. №99.

2. Билгесез кабер ташы, XVI гасыр.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллааһү Тәбәәракә вә Тәгаалә
2) күллү мән галәйһә фәән вә йәбкаа вәҗһү
3) Раббикә зүүл-җәләәли вәл-икраам
4) ...».

Уң ягы (калкытып язылган): «Кааләл-нәбии галәйһис-сәләәм әд-дүнйәә...».

Сул ягы (калкытып язылган): «Кааләл-нәбии галәйһис-сәләәм...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә әйтте:
2) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани, фәкать Раббыңның
3) Олуглык һәм хөрмәткә ия булган йөзе генә калачак.
...».

Уң ягы: «Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) әйтте: «Дөнья – ...».

Сул ягы: «Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) әйтте...».

Таш үлчәмнәре: 82x54x26.

Югары Сәрдә авылының борынгы (көнчыгыштагы) зираты

1. Бути шәех Дәрвиш улына куелган кабер ташы, 1520–1521 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллааһү Сүбхәәнәһү вә Тәгаалә күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) кааләл-нәбии галәйһис-сәләәм әд-дүнйәә сәәгатүн фә-
3) -җгальһәә таагаһ садәка расүүлүллааһ
4) тарих тукуз йөз йегерме йите дә
5) шәйех Дәрвиш углы Бути
6) даре фәнадан даре бәкага рихләт кыйлды».

Уң ягы (калкытып язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Сул ягы (калкытып язылган): «Әраад-дүнйәә хараабән бигътибәәрии фәлә йәбка мүдәмән бил-караарии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
2) Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) әйтте: «Дөнья бер сәгатьлек,
3) аны [Аллаһка] итагать белән үткәр». Аллаһ илчесе дөрес әйткән.
4) Тугыз йөз егерме җиенче [елда]

5) шәех Дәрвиш улы Бути
6) фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Таш үлчәмнәре: 101x43x12.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 12 б. №100

2. Билгесез кабер ташы, 1476–1477 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Әгуузү билләәһи минәш-шәйтааниржәиим бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим кааләл-нәбии галәйһис-сәләәм әд-дүнйәә...
2) кааләл-нәбии галәйһис-сәләәм әлкабру раудатүн мин рийәәд-
3) -ыйль-җәннәти әү хүфратүн мин хүфәрин-нәйраан садәка расүүлүллаах
4) тарих сигез йөз сиксән бердә
5) ...
6) ...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ләгънәт кылынган шайтаннан Аллаһка сыенам. Шәфкатьле, рәхимле Аллаһ исеме белән. Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) әйтте: «Дөнья – ...».
2) Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) әйтте: «Кабер – җәннәт бакчаларыннан
3) бер бакча яки утлар чокырларыннан бер чокыр. Аллаһ илчесе дөрес әйткән.
4) Сигез йөз сиксән беренче [елда]
5) ...
6) ...».

Таш үлчәмнәре: 94x52x12.

3. Билгесез кабер ташы, XVI гасыр.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягындагы язулары бөтенләй күренмәс хәлгә килгән.

Уң ягы (калкытып язылган): «Кааләл-нәбии галәйһис-сәләәм...».

Сул ягы (калкытып язылган): «Кааләл-нәбии галәйһис-сәләәм...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Уң ягы: «Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) әйтте...».

Сул ягы: «Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) әйтте...».

Таш үлчәмнәре: 136x49x23.

4. Билгесез кабер ташы, XVI гасыр.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаahү Тәбәәракә вә Тәгааләә
2) күллү мән галәйһәә фәән вә йәбкаа вәҗһү
3) Раббикә зүүл-җәләәли вәл-икраам
4) тарих тукуз [йөз]...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә әйтте:
2) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани, фәкать Раббыңның
3) Олуглык һәм хөрмәткә ия булган йөзе генә калачак.
4) Тугыз [йөз]...».

Таш үлчәмнәре: 158x51x11.

5. Билгесез кабер ташы фрагменты, XVI гасыр.

Язулары бөтенләй күренмәс хәлгә килгән.

Таш үлчәмнәре: 47x44x13.

6. Билгесез кабер ташы, 1499–1500 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаahү Тәбәәракә вә Тәгааләә
2) күллү мән галәйһәә фәән вә йәбкаа вәҗһү
3) Раббикә зүүл-җәләәли вәл-икраам
4) тарих тукуз йөз биш йылда
5) ... гыйалы...
6) ...».

Уң ягы (калкытып язылган): «Әраад-дүнйәә хараабән бигътибәәрии фәләә йәбка мүдәмән бил-караарии».

Сул ягы (калкытып язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә әйтте:
2) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани, фәкать Раббыңның
3) Олуглык һәм хөрмәткә ия булган йөзе генә калачак.
4) Тугыз йөз бишенче елда
5) ... хатыны...
6) ...».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Таш үлчәмнәре: 136x44x23.

7. Билгесез кабер ташы, XVI гасыр.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәбәәракә вә Тәгааләә
2) күллү мән галәйһәә фәән вә йәбкаа вәҗһү
3) Раббикә зүүл-җәләәли вәл-икраам
4) тарих тукуз йөз...».

Уң ягы (калкытып язылган): «Кааләп-нәбии галәйһис-сәләәм әд-дүнйәә сәәгатүн фәҗгальһәә таагаһ».

Сул ягы (калкытып язылган): «Кааләп-нәбии галәйһис-сәләәм әд-дүнйәә мәзрагатүл-әәхыйраһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә әйтте:
2) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани, фәкать Раббыңның
3) Олуглык һәм хөрмәткә ия булган йөзе генә калачак.
4) Тугыз йөз...».

Уң ягы: «Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) әйтте: «Дөнья бер сәгатьлек, аны [Аллаһка] итагать белән үткәр».

Сул ягы: «Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) әйтте: «Дөнья – ахирәт басуы»«.

Таш үлчәмнәре: 112x56x23.

8. Мирхәсән Мөсаһир улына куелган кабер ташы, 1536–1537 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәбәәракә вә Тәгааләә
2) күллү мән галәйһәә фәән вә йәбкаа вәҗһү
3) Раббикә зүүл-җәләәли вәл-икраам
4) тарих тукуз йөз кырык өчдә
5) Мөсаһир углы Мирхәсән даре фәнадин
6) даре бәкага рихләт кыйлды».

Уң ягы (калкытып язылган): «Әраад-дүнйәә хараабән бигътибәәрии фәләә йәбка мүдәмән бил-караарии».

Сул ягы (калкытып язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә әйтте:
